«Күчеп йөрүче ХӘБӘР»ләр «Шәһри Казан»да

Бу проектка барлыгы 150ләп рәссам кушылып, Татарстан, Саха-Якутия, Башкортстан, Мари Эл, Чувашия, Мордовия, Удмуртия, Коми, Молдова (Гагаузия), Кыргызстан, Казахстан, Төрекмәнстан, Төркиядән 300гә якын эш кабул ителә. Ул эшләрнең бер өлеше белән хәзерге вакытта «Шәһри Казан» редакциясенең күргәзмәләр залында танышырга була.

6 БИТ

Беркемгә дә кирәкмисеңме?

Үзеңнең беркемгә дә кирәк булмавыңны тою – бик яман хәл. Тормыш кануннарына төшенә генә башлаган сабыйга мондый очракта нишләргә? Өлкәннәрнең, иң кадерле кешеләрнең хыянәтен ничек кичерергә?

5 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Җомга | 10.03.2017 | № 25 (5787)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

КАЗАНДА ЙОРТЛАР ДА «КАЗАНЛЫ»

Башкалада быел күпфатирлы 244 торак йорт, 22 мәгариф учреждениесе, 8 балалар бакчасы һәм элеккеге 5 тулай торак комплексы төзекләндерелә, 141 яңа лифт куела.

Дамир БӘДРИЕВ

– Торак йортларны төзекләндерүгә тотыла торган акчаларның яртысы – халыкныкы, ә күпме «сөңге» сындырылды. Кирәкме бу эш? Акча кая китә, халыкка барып җитәме? Башка шәһәрләр капремонт турында, шушы мәсьәләдә гәп корган арада, Татарстанда бу инде чишелде. Казан – халык белән уртак тел тапкан беренче шәһәр. Нәтиҗәләр үзләре үк сөйләп тора, – диде мэр Илсур Метшин шәһәр башкарма комитетында узган киңәшмәдә.

Торак йортларны капиталь төзекләндерүгә быел 1,5 миллиард сум билгеләнгән. Шуның 52 проценты – торак милекчеләренеке, 29 проценты – Татарстан, 19 проценты – шәһәр бюджетларыннан.

Авиатөзелеш районында – 24, Вахитов районында – 29, Киров районында – 25, Мәскәү районында – 44, Яңа Савин районында – 29, Идел буе районында – 24, Совет районында 69 күпфатирлы йорт икенче сулыш алачак.

– Түбә ябу һәм торба алмаштыру белән генә чикләнмибез, – дип фикерләрен уртаклашты мэр Илсур Метшин. – Йортларның инженерлык челтәренең яңартылуы мөһим: һава торышына карап үзкөйләнелә торган механизмнар, хисаплагычлар, җылылык казаннары куела.

Казанда 2012 елдан башлап, күпфатирлы йортларга җылы су әзерләүче механизм, ягъни автоном эшләүче казан урнаштырыла. Программа кысаларында инде 264 күпфатирлы йорт казанлы булган.

– Мондый казаннар көйләнгән йортларда җылы су белән тәэмин итүдә җылылык югалуы – 20-40 процентка, ә җылы су өчен түләүне 20 процентка киметергә мөмкинлек бирде. ТЭЦлардан сузылган торбаларны төзекләндерү өчен ишегалларын әледән-әле актарырга туры килә. Торбаларны ремонтлаганда җылы су бирү дә өзелә.ТЭЦлардан сузылган җылы су челтәреннән баш тарту ишегалларында буш мәйданнар барлыкка китерә, – дип әйтеп үтте үзенең чыгышында торак-коммуналь хуҗалык комитеты рәисе Искәндәр Гыйниятуллин.

Быел капиталь төзекләндерү исемлегенә кертелгән элеккеге тулай тораклар: Бертуган Касыймовлар урамы, 6, Качалов урамы, 84, Липатов урамы, 15, Повстанческая урамы, 8 һәм Повстанческая урамы, 10.

2017 ел – «Энергетик», «Ритм», «Авангард», «Молодая гвардия», «Юность», «Арена», «Родник», «Ракета» үсмерләр клублары өчен сөенечле ел.

– Әлеге клубларда капиталь ремонт эшләре башкарылгач, офис җиһазлары белән спорт җиһазлары да яңалар куелачак. Җиһазлар өчен акча кучерелгән. Алты клуб физик мөмкинлекләре чикле балалар мәнфәгатен исәпкә алып төзекләндерелә, – дип күңелле хәбәр ирештерде Искәндәр Гыйниятуллин.

Казанда быел 13 мәктәп һәм гимназия капиталь төзекләндерелә. Республика программасы кысаларында башкаладагы мәктәпләрнең 88 проценты яңартылды. 30 елдан артык файдаланыла торган тагын дүрт мәктәп сабыр итә, аларны киләсе елда колачлау ниятләнелә.

Капиталь ремонт үткәрүдә Россия һәм Татарстан җитәкчелегенең ярдәме зур булуы телгә алынды.

– Программа гаять әһәмиятле, – диде мэр Илсур Метшин, сөйләшүгә йомгак ясаганда. – Халык белән эшләргә өйрәндек, подрядчы оешмалар конкурс аша сайлап алына. Капиталь ремонт бик четерекле нәрсә, башкарылган ремонт эшләренә риза булмаучылар юк диярлек. Сыйфат – безнең өчен дә, подрядчылар өчен дә төп таләп. Шулай да янә искәртеп куям, барлык эшләр торак милекчеләре белән килешенеп эшләнелсен. Башкарылган эш халык тарафыннан тикшерелеп кабул ителә.

Татарстанда быел күпфатирлы 998 йорт, 44 клуб, 10 колледж, 29 үсмерләр клубы, 28 социаль хезмәт күрсәтү учреждениесе, 42 җирле үзидарә бинасы капиталь төзекләндерелә.

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Германиягә эш сәфәре кысаларында, BMW автоконцерны заводында булды. Лейпцигта BMW заводы – дөньядагы иң заманча һәм иң экологик авто җыю предприятиеләренең берсе. Бирeдә көн саен конвейердан 740 машина чыга. Алар – 1нче һәм 2нче серия BMW автомобильләре, шулай ук BMW i3 һәм BMW i8 электромобильләре. Завод төзелешенә инвестицияләрнең гомуми күләме 2,2 млрд еврога якын. Рөстәм Миңнеханов BMW автомобилен үзенчә сынады – BMW i8 спорт версиясе автомобилен йөртеп карады.

tatarstan.ru

БЕЗГӘ КИЛЕГЕЗ

Эш сәфәре барышында Миңнеханов «Лейпциг ярминкәсендә» INTEC 2017 һәм Z 2017 халыкара күргәзмәләрдә булды. Z 2017 – модуль, технология һәм запас частьлар буенча халыкара күргәзмә. Ул ике елга бер тапкыр үткәрелә һәм Европадагы эре профильле күргәзмәләрнең берсе булып санала. INTEC шулай ук ике елга бер уздырыла торган махсус машина һәм станоклар төзелешендә махсуслашкан халыкара күргәзмә булып тора.

Соңрак Президент Саксония премьер-министры Станислав Тиллих белән очрашты. Яклар үзара ярдәм итешү өлкәсендә тупланган тәҗрибә кысаларында алга таба хезмәттәшлек итү мәсьәләләре хакында фикер алышты, дип хәбәр итә Президентның матбугат хезмәте. Рөстәм Миңнеханов Ирекле Саксония дәүләтенә килүенә шат булуын билгеләп үтте.

– Безнең төбәкләрнең хезмәттәшлеге – Россия – Германия мөнәсәбәтләрен ныгытуда өлеше зур, – диде ул.

Алга таба Рөстәм Миңнеханов Станислав Тиллихны Казанга килергә чакырды һәм Конфедерация Кубогы кысаларында узачак Германия һәм Чили җыелма командалары арасындагы футбол матчы алдыннан 2017 елның 21 июнендә Казанда Татарстан – Саксония эшче төркеменең утырышын үткәрү хакында килешү барлыгын хәбәр итте. Станислав Тиллих Рөстәм Миңнехановка Казанга чакырганы өчен рәхмәт белдерде һәм Татарстан партнерлары белән кооперацияне Россия базарына чыгу өчен яхшы мөмкинлек дип атады.

Z/Intec сәнәгать күргәзмәсе ачылышы уңаеннан үткәрелгән рәсми кабул итү чарасында ясаган чыгышында, Рөстәм Миңнеханов Германиянең Татарстанның әйдәп баручы тышкы икътисади партнеры булуын, товар әйләнешенең 1 миллиард евродан артып китүен ассызыклады.

– Без Германия һәм Саксония компанияләренең Россия базарында эшләү өчен Татарстанны старт мәйданчыгы итеп сайлавына карата кызыксыну белдерәбез. Без ике якка да файдалы нигездә хезмәттәшлек итүгә әзер һәм сезне республикада көтеп калабыз, – дип мөрәҗәгать итте Татарстан Президенты.

Германиягә эш сәфәре кысаларында Рөстәм Миңнеханов Лейпцигта «Аргамак» татар яшьләре берләшмәсе вәкилләре белән дә очрашты. Бүгенгә берләшмәдә 30 активист бар. Бу яшьләр – төрле өлкәләрдә эшләүче белгечләр. Рөстәм Миңнеханов очрашу мөмкинлеге өчен, шулай ук татар халкының гореф-гадәтләрен, мәдәниятен һәм телен саклап калу мәсьәләләренә битараф булмаганнары өчен барысына да рәхмәт белдерде.

Табибларның хезмәт хакы икеләтә артачак

Татарстанда медицина хезмәте күрсәтүнең сыйфаты, аны яхшыртуда нинәр эшләргә кирәклеге турында «Бердәм Россия»нең Татарстан төбәге бүлегендә узган «Партия лигасы» дискуссия клубы утырышында сөйләштеләр. Журналистларның, тамашачыларның сорауларына Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов, Татарстанның сәламәтлек саклау министры Адел Вафин, Казан дәүләт медицина университеты ректоры Алексей Созинов, Анжела Вавилова исемендәге фонд идарәсе рәисе Владимир Вавилов һәм «Акцент» хокук саклау төркеме җитәкчесе Булат Мөхәммәтҗанов җавап бирде.

Автор фотосы

Айрат Фәррахов әйтүенчә, Россия бюджетыннан сәламәтлек саклау өлкәсенә 2, 8 триллион сум акча бүлеп бирелгән. Ни дисәң дә, сәламәтлек саклау системасы дәүләт хезмәтләре арасында иң зур ихтыяҗга ия тармакларның берсе булып санала. Татарстанның социаль-икътисади мониторинг буенча комитет мәгълүматлары буенча, 2016 елда республика халкының 75,1 проценты медицина хезмәтеннән канәгать булуын белдергән. Адел Вафин әйтүенчә, 2013 елда бу күрсәткеч 62,2 процент кына булган. Шулай да зур суммалар тотылып та, кайбер мәсьәләләрнең чишелми калуы халыкны борчый. Күбесе даруларның кыйммәт булуы, белгечләргә язылып булмау, табибларның дәвалау сыйфаты, сырхауханәләрнең иске булуы, ришвәтчелеккә канәгатьсезлек белдереп мөрәҗәгать итә. Былтыр граждannardan коррупция очракларына бәйле рәвештә килгән мөрәҗәгатьләрнең 15е буенча җинаять эше ачылган. Медицина өлкәсендәге тәртип бозулар уңаеннан 39 эш тикшерүдә. Сәламәтлек саклау министрлыгы Татарстан Хөкүмәте белән берлектә медицина хезмәте күрсәтү сыйфатын яхшырту буенча ныклы эш алып бара. Былтыр гына да медицина өлкәсен модернизацияләү өчен бюджеттан 4 миллиард сумнан артык акча бүлеп бирелгән. Авыл җирендә фельдшер-акушерлык пунктлары төзүгә, кадрлар мәсьәләсенә зур игътибар бирелә. Сәламәтлек саклау министрлыгы үзе дә тәртип бозу очракларын тикшерә, эшләрне хокук саклау органнарына тапшыра.

Халыкка тыңгы бирмәгән сырхауханәләр проблемасы да бүген кискен тора. Әле күптән түгел генә Президент Рөстәм Миңнеханов Татарстандагы сырхауханәләрне төзекләндерү буенча махсус программа кабул ителәчәген әйткән иде. Сырхауханәләр белән бәйле вазгыятьне яхшырту максатыннан, республикада «Дустанә сырхауханә» проекты эшли башлады. Хәзер табибны көтү вакыты 10 минутка кадәр кыскарды, белгеч тә авырууга күбрәк вакытын багышлый ала. Сырхауханәләрдә эш камилләште.

– Татарстанда төзекләндерү, модернизация таләп ителгән 190 сырхауханә бар. Программа өч елга исәпләнгән. Беренче чиратта, модернизацияләнергә тиешле учреждениеләр исемлеген якын арада Президентка тәкъдим итәчәкбез. Быел 60лап сырхауханә яңарыр дип көтелә, аеруча балаларны дәвалау учреждениеләренә игътибар бирергә кирәк. Бик катлаулы хәлдәге сырхауханәләр бар. Әйтик, Идел буе районындагы 21нче сырхауханә 25 мең кешегә генә исәпләнгән, әмма анда 65 меңнән артык кеше теркәлгән. Бу проблеманы хәл итү өчен, сырхауханәгә өстәмә 10 мең квадрат метр тирәсе корылма төзү тәкъдим ителде. Бирeдә консультатив диагностика үзәге урнашачак. Тәҗрибәле белгечләр авыруларны тикшерәчәк. Хәтта онкология табиблары да бирeдә эшләячәк, – ди Адел Вафин.

Дискуссия барышында үзебездә җитештерелгән медицина җиһазларының югары сыйфатлы булуына да басым ясалды. Әйтик, Япониядә студентлар безнең җиһазларны кулланып, тәҗрибәләр уздыралар икән.

Владимир Вавилов фикеренчә, медицина сыйфатын яхшыртуга тәэсир итә торган алымнарның берсе – табибларның хезмәт хакын арттыру. Бу хакта әле шушы көннәрдә генә Россия Президенты Владимир Путин да әйткән иде. Адел Вафин әйтүенчә, 2018 елга табибларның хезмәт хакын 180 процентка арттыру күздә тотыла. Шулай ук табибларның гомерен иминиятләштерү дә мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора.

Ничек кенә булмасын, халыкның үтенеч-мөрәҗәгатьләре игътибарсыз калмасын. Юк кына мәсьәләне хәл итүдән дә сыйфат дәрәҗәсе яхшыра бит. Булат Мөхәммәтҗанов китергән мисал моңа дәлил: «2013 елда медицина сыйфатына кагылышлы «кайнар элемтә» оештырган идек. Ни хикмәт, шалтыратучыларның 95 проценты медицина учреждениеләрендә бахилларны сатып алырга кушуларыннан зарланды. Нәтиҗә көттермәде – бүген бу проблема тулысынча хәл ителде».

Эльвира МОЗАФФАР.

Нюша белән футболны нәрсә бәйли?

Конфедерация Кубогына 100 көн калды

Конфедерация Кубогы башланырга 100 көн калды. Димәк, Казан дөнья дәрәҗәсендәге зур вакыйганы зур түземсезлек белән көтә.

Әзерлек эшләрен чемпионат илчеләре волонтерлардан башларга булды. Чөнки нәкъ менә алар илебезнең йөзе, кунакчыллык билгесе булып торачак бит. Бу уңайдан Казан шәһәренең башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Дамир Фәттахов белән Россиянең танылган җырчысы, композитор Нюша (Анна Шурочкина) булачак берничә дистә волонтердан имтихан алды. Аларны волонтер булырга теләгән егетләр һәм кызларның инглиз телен белү дәрәҗәсе, волонтерлык тәҗрибәсе кызыксындырды. Шунысы гаҗәпләндерде бу җаваплы эшкә яшьләр генә түгел, ә урта буын, өлкән яшьтәгеләр дә теләп алына икән. Мәсәлән, Гөлнара Мөбарәкшина хәзерге вакытта декрет ялында. Моңа кадәр ул 2013 елгы Универсиада вакытында, быел «WorldSkills» эшче һөнәрләр чемпионатында үзен волонтер буларак сынап карый.

tatar-inform.ru

– Баламны әбиләре карарга ярдәм итәчәк. Декрет ялымны үзем өчен дә, башкалар өчен дә файдалы итеп үткәрәсем килә. Шундый зур вакыйга гомердә бер генә була. Волонтерлык минем өчен саф һава кебек: яңа танышлар, тәҗрибә туплау мохите, – диде яшь ана.

Дамир Фәттахов волонтерлыкка кандидатларның беренче чиратта кеше белән аралаша белүенә, кунакчыллыгына игътибар итте.

– Волонтер юл күрсәтүче кеше генә түгел, ул – республиканың йөзе. Аның максаты – спортчыларга, җанатарларга Казан халкының кунакчыллыгын күрсәтү. Аның төп кораллы — елмаю. Волонтерлар һәр кунакта шәһәребезгә карата мәхәббәт уятырга тиеш, – диде ул.

Элек спортның бу төре белән артык кызыксынмаган Нюша исә булачак волонтерларга футбол белән бәйле сораулар яудырды. Ул үз вазифасына җитди караган. Хәзер менә бер матчны да калдырмый күзәтеп бара икән.

– Волонтер аралашучан, актив булырга тиеш. Сайлап алу турында мин аларның нәкъ менә шул сыйфатларына игътибар иттем. Минем максат үз аудиториямә, аеруча да яшьләргә булачак чемпионат турында сөйләү. Үсеп килүче буынны спорт белән шөгыльләнергә өндим хәзер. Биредә үзем өчен дә бик кызыклы мәгълүмат алам. Футбол белән алдан бик кызыксынмаган булсам да, гаиләм спортка якын. Сеңлем – синхрон йөзү буенча Олимпия чемпионы. Хәзер менә футбол буенча белемнәрне тирәнәйтәбез, – диде җырчы.

Соңыннан Нюша Иннополис университетында мәктәп укучылары һәм студентлар арасында чемпионатка кагылышлы викторина оештырды. Сорауларга дөрес җавап бирүчеләргә җырчы истәлекле бүләкләр тапшырды.

Алисә САБИРОВА.

Элеккеге хәрби госпиталь бинасы 2012 елда ябылган иде. Дүрт ел буш торганнан соң аны Казан федераль университетына тапшырдылар. Шуннан соң озак та узмый, белем бирү йорты биредә зур төзекләндерү эшләре башлап җибәрде. Яңа уку елында монда КФУның Фундаменталь медицина һәм биология институты кафедралары, лабораторияләре һәм аудиторияләре урнашачак.

Госпитальдән – медицина үзәгенә

Әлегә берничә корпусны берләштергән зур мәйданда төзелеш эшләре гөрли. Ә яңа уку елы башыннан ул студентлар белән кайнап торачак. Элеккеге госпитальнең беренче корпусында – стоматология һәм имплантология үзәкләре, икенчесендә – студентлар һәм аспирантлар өчен лабораторияләр, өченчесендә симуляция үзәге булачак. Монысында студентлар тренажерларда операцияләр ясарга өйрәнәчәк. Шулай ук хәрби музей да оештырырга планлаштыралар.

Казан (Идел буе) федераль университеты ректоры Илшат Гафуров әйтүенчә, тарихи бинаны реставрацияләү җиңел эш түгел, чөнки, беренчедән, бу өлкәдә эшләүче белгечләрне табу авыр булса, икенчедән, чыгымнар да зур.

– Элеккеге госпитальне төзекләндерү өчен 300 млн сум тирәсе акча тотылачак. Тагын 460 млн җиһазлар алу өчен китәчәк. Болар барысы да – университет акчалары. КФУга тапшырылган сәламәтлек саклау объектларын төзекләндерүгә тотылган акчалар исә миллиард сум тирәсе, – ди ул.

Бина 1840 елда төзелгән. Шуңа күрә аны төзекләндерүгә карата Мәдәният министрлыгының да таләпләре катгый. Биредә барысы да ничек бар, шул рәвешле сакланырга тиеш.

– Сакланган фотосурәтләр буенча бинаны элеккечә эшлибез. Ишек, баскычларны шуларга нигезләнеп торгызабыз. Бу катлаулы эш, чөнки белгечләр дә юк дәрәҗәсендә. Аннан соң агач түшәмнәр черегән иде, мөмкин булганнарын, реставрацияләп, яңадан торгыздык. Бөтенләй начар хәлдә булганнарын тимергә алыштырдык, – ди Илшат Гафуров.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

ХӘРӘКӘТ ИМИНЛЕГЕ

Казанда 20 марттан мәктәп укучыларының язгы каникулы башлана.

Сак йөрегез... каникул!

Кызганыч, каникул чорында балалар катнашындагы юл-транспорт һәлакәтләре саны артучан. Чөнки балалар күп вакытларын урамда үткәрә. Ел башыннан башкалада балалар катнашында 30га якын юл һәлакәте теркәлде. Казан шәһәре буенча эчке эшләр идарәсенең ЮХИДИ бүлеге хезмәткәрләре, аварияләрне чикләү максатында, мәктәпләрдә лекцияләр һәм әңгәмәләр оештырырга керешә.

Шәһәр урамнарында 21-23 мартларда автомобильдә балаларны йөртү таләпләрен үтәмәүче ата-аналарны ачыклау буенча рейдлар уздырыла. 22-24 мартларда юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозучы җәяүле өлкәннәр һәм балалар күз уңына алыначак.

Балалар катнашындагы һәр 26 авариянең 22сендә транспорт чарасын идарә итүче гаепле. Мәгариф һәм мәдәният учреждениеләре янында тизлек режимын катгый сакларга кирәк. Җәяүлеләр светофорның яшел уты кабынган вакытта да ашыкмасын иде. Транспорт чаралары тәмам туктап беткәч кенә урам аша чыгу зарур.

Кошлар белән бергә авырулар кайта

– Соңгы вакытта үзәк матбугат чараларында Татарстанны себер түләмәсе буенча имин булмаган территория буларак телгә алалар. Берничә көн элек кенә, республикада кош гриппыннан үлү очрагы бар, дип язып чыктылар. Бәхеткә, бездә узган ел да, әле дә мондый авырулар ачыкланмады, – дип белдерде кичә журналистларга Татарстан Министрлар кабинеты каршындагы ветеринария идарәсенең бүлек җитәкчесе Александр Козлов.

Быел да әлеге авырулар Татарстанны читләтеп узар дип өметләнә белгечләр, чөнки моның өчен тиешле чаралар күрелә. Кош грипы Тыва Республикасында, Әстерхан, Ростов өлкәләрендә һәм башка төбәкләрдә табылган. Тикшеренүләр санитар таләпләрнең сакланмавын ачыклаган.

Кош гриппы Татарстан өчен нәрсәсе белән куркыныч соң? Республика кош үрчетү, кош ите җитештерү буенча алдынгы урыннарда тора. Әлеге тармак алга таба да үсеш алсын һәм табыш китерсен өчен, кошларның сәламәт булуы кирәк.

Кош гриппы кеше сәламәтлеге өчен куркынычмы? Александр Козлов бу сорауга да ачыклык кертте.

Моңа кадәр үткәрелгән тикшерүләр әлеге вирусның кеше өчен куркыныч булмавын раслады, әмма бу очракта бер генә табиб та тулысынча ышандыра алмый, чөнки вируслар бик тиз яраклашырга – мутацияләнергә сәләтле, – диде ул.

Тиздән җылы яклардан кошлар кайтачак. Бу исә авыру барлыкка килүдә тагын да зуррак куркыныч тудырачак.

Кош үрчетү предприятиеләре хуҗалары һәм гади халык нәрсәгә игътибар итәргә тиеш?

Йорт кошы белән кыргый кошның бер-берсе белән бәйләнешен булдырмас өчен, эре предприятиеләр кошларны ябык режимга күчерергә тиеш. Хәтта күгәрчен, сыерчык кебек кошлар да билгеле бер куркыныч тудыра.

Мондый типта эшләгән предприятиеләрнең хезмәткәрләренә дә таләпләр катгый – аларга өйләрендә кош-корт асрарга ярамый.

Махсус киемнәрне эшкәртергә, аяк киемнәрен алыштырырга, якын-тирәдә урнашкан территорияләрне дезинфекцияләргә кирәк.

Хуҗалыктагы кошларның үз-үзләрен тотышларында үзгәрешләр булса (температуралары күтәрелсә, су эчәргә һәм ризык ашарга теләмәсәләр, канатлары салынып төшсә, хәлләре булмаса) яки кинәт үлеп китү очраклары артса, диагнозын ачыклар өчен, мал табибларына мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Гади халыкка исә кулларны ешрак юарга киңәш ителә. Йомырканы яхшылап юарга һәм кимендә ун минут пешерергә кирәк. Ә тавык, күркә ите ярты сәгатьтән дә кимрәк пешмәскә тиеш. Зарарланган итне ашаган кешегә мондый очракта зыян булмаячак.

Зөһрә МОСТАФИНА.

«WORLDSKILLS» КӨНДӘЛЕГЕ

Алар кулында кеше гомере

Кеше бәла-казага тарыганда, беренчел ярдәм күрсәтүдән гыйбарәт аларның эшләре. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы коткаручыларына, көн дәвамында гаиләләрен, үзләрен онытып, кеше гомерен саклап калу өчен көрәшергә туры килә. Бу һөнәрне үзләштерү өчен зур һәм батыр йөрәкле булырга кирәктер. Әнә шундый яшь егет һәм кызлар Тәтеш дәүләт гражданнарны яклау көллиятендә белем ала.

Алисә САБИРОВА

Бу – республикада коткаручылар әзерләүче бердәнбер уку йорты. Укучыларның барысы да хәрбиләр кебек махсус формадан йөри. Элек мин бу һөнәрне бары егетләр генә сайлый дип уйлый идем. Укучыларның яртысы кызлар булуы шаккатырды. Алар да егетләр белән бертигез дәрәҗәдә нормативлар бирә, физик һәм рухи көч туплый.

18 яшьлек Кристина Морозкина да кечкенәдән коткаручы булырга хыялланган. Бүген ул – республиканың иң яхшы студент-коткаручысы. Әле күптән түгел командасындагы дүрт егет белән «WorldSkills» эшче һөнәрләр чемпионатының төбәк этабында җиңү яулап кайттылар. 16 мартта исә аларны Мәскәүдә тагын бер сынау көтә.

– Бу һөнәр миңа бик кызык булып тоелды. Егетләр кебек, мин дә корал белән җенләнәм. Укуның теоретик өлеше аеруча да җиңел бирелә. Елына ике тапкыр ГТО нормалары тапшырабыз. Иң авыры – физик әзерлек нормативлары тапшыру. Әйтик, республика чемпионатында миңа барлык эшләрне дә егетләр белән бертигез дәрәҗәдә башкарырга туры килде. Тауга менү кебек күнегү дә авыр бирелә. Егетләр белән кызлар эше бер генә җирдә аерыла: егетләр юл һәлакатеннән соң машинадан кешене чыгарырга тиеш булса, җәрәхәт алучыга беренчел ярдәмне мин күрсәтергә тиеш. Бу эшкә барлыгы 8 минут вакыт сарыф ителергә тиеш. Коткаручы формасын кию буенча да ярыш бар. Аны «бишле»гә бирү өчен 21 секунд вакыт бирелә, – ди Кристина.

Вазифасы авыр булуга карамастан, ул тормышын коткару эшенә багышламакчы.

Башка һөнәри белем бирү учреждениеләрендәге кебек үк, биредә дә «WorldSkills» стандартлары буенча укыталар. Шуңа да алар яңгын сүндерүчеләрнең махсус күнекмәләрен ел дәвамында яхшы үзләштергән. Ләкин һәр уку йортындагы кебек биредә дә чемпионатка әзерлек эшләрендә җиһазлар җитми икән.

– Безнең көллияттә янгын сүндерүчеләр өчен каршылыклы полоса юк. Лабиринттан чыгу, торбадан төшү, җимерек күпердән бару, асылмалы баскычтан менү кебек һәр биремне аерым өйрәнәбез. Юл һәлакәтеннән соң кешене җимерек машинадан дөрес итеп чыгара белергә дә кирәк. Аны өйрәтү өчен, укучыларга иске «Волга» машинасын көйләдек. Алар аны аркылыга-буйга туралап бетерде инде, – ди укытучылары, республика буенча «WorldSkills» чемпионаты эксперты Игорь Мамкин.

Аның сүзләренчә, «WorldSkills» чемпионаты – укучыларга яхшы эшкә урнашу мөмкинлеге.

– Быелдан Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы урта һөнәри белем бирүче уку йортларында имтиханнарны «WorldSkills» стандартлары буенча тапшырырга мәҗбүр итте. Бу исә һәр укучының белем дәрәҗәсе Европа стандартына тиң булырга тиеш дигән сүз. Ә чемпионатның үзендә катнашучыларга махсус сертификат тапшырыла. Ул исә студент алдында күп кенә зур оешмаларның ишеген ача, – диде Игорь Мамкин.

«WorldSkills»ның төбәкара этабында 15 команда көч сынашачак. Биш җиңүче Краснодарда Россия этабын уза. Ил күләмендә җиңгән команда Абу-Даби шәһәренә халыкара чемпионатка юллама алачак.

КАЗАН БАКЧАЛАРЫ

«Иптәш Ленин» чакыра

Бүген Ленин бакчасының катлаулы үткәне турында бәян итәргә булдым. XIX гасыр урталарында барлык шәһәрләрнең төзеклеген андагы яшеллекләрнең күплеге белән бәйләп караганнар. Шәһәрдә бакчаларга урын бүлеп бирә башлыйлар, һәр урамда, торак йортлар каршысында кечкенәрәк бакчалар утырталар. Болар, беренчедән, шәһәргә ямь өстәсә, икенчедән, торак җирләрнең «үпкәсе» буларак хезмәт итәләр.

XVIII гасыр башыннан XIX гасыр башына кадәр Казанда алты бакча булган, ә XIX гасыр яртысыннан XX гасыр башына кадәр инде 20дән артык бакча теркәлгән. Казанның шәһәр бакчалары шәхси бакчалардан әллә ни аерылып тормаган. Тора-бара үзгәрешләр сизелә башлый: сулыклар буена таллар, куаклар утыртыла, юллар да сукмактан аерыла, вак таш түшәлә. Шәһәр бакчаларына күңел ачу, төрле чаралар үткәрү өчен уңайлыклар тудыру теләге туа. Кинотеатрлар, фонтаннар… Аннары оркестр өчен, бию мәйданчыклары, кәмитләр урнаштыру ихтыяҗы туа. Соңгарак туклану урыннары, спорт мәйданчыклары барлыкка килә.

Николай бакчасын карап үтик. Бу урында элек сазлык булып, тирә-ягында тимерче алачыклары тезелеп китә. Шуңа күрә дә бу урынны Тимерчеләр мәйданы дип йөртә башлыйлар. 1842 елдагы янгын хәлләрне үзгәртә. Губернатор Шипов Казан үзәгенең яңа планын раслый. Аның буенча сасы күлдән котылырга тиеш булалар. Шуннан соң, сазлыкка җир ташып, аны күмәләр. Андагы мәйдан да шактый күтәрелә. Бу эшләр император Николай I вакытында башкарылганга күрә, мәйданның да исемен Николай мәйданы дип атыйлар. 90нчы еллар ахырында бу мәйданда солдатлар өчен плац-парад ясыйлар. Мәйдан тагын пычрана башлый.

1888 елда агач цирк бинасы төзергә уйлыйлар, әмма шәһәр башлыклары каршы чыга. 1890 елда Казанда Бөтенроссия фәнни-сәнәгать күргәзмәсе булып үтә. Аның төп өлеше Николай мәйданында урнаша. Күргәзмә бинасы архитектор Генрих Руш сызымнары буенча төзелә.

Казан губернаторы һәм эчке эшләр министры раслаганнан соң, 1891 елда Николай бакчасы ясарга дигән боерык чыгарыла. Сәүдә биналары төзелә башлый, яшелләндерү дәвам итә. Шул вакыттан бирле Николай бакчасын халык ял итү урыны итеп саный башлый. Монда төрле бәйрәмнәр үткәрелә, кәмитләр, таганнар ясала, башка җирләрдән килгән артистлар үз һөнәрләрен күрсәтә.

1894 елның җәендә бакчада фонтан эшли башлый, 1924 елда дөнья пролетариаты юлбашчысы хөрмәтенә Николай бакчасын Иптәш Ленин исемендәге бакча дип атый башлыйлар. Яңа исем белән бакча үзгәрешләр дә кичерә. Өске якта университет бакчасы белән тоташтырылган баскыч барлыкка килә. Аның янына пролетариат юлбашчысы Ленинга һәйкәл куела. Баштарак бронзадан бюст урнаштырсалар, аннары ул басып торучы Ленин белән алыштырыла. Юлбашчы һәйкәлен үзенә куйдыру өчен, тагын дүрт урын дәгъвалый: Ирек мәйданы, Кабан күле яр буе, вокзал яны мәйданы, елга порты мәйданы. Бәйгедә иң уңышлы урын дип Иптәш Ленин исемендәге бакчаны сайлап алалар.

1931 елда җәйге кинотеатр төзелә, ә аның янында ачык эстрада, волейбол мәйданчыгы урын ала. Бакчаның түбәнге өлеше электрлаштырылмау сәбәпле, төрле чаралар үткәреп булмый, фонтан да кайбер көннәрне эшләми, эскәмияләр, чүплек савытлары юк диярлек. Бага на янына радио тыңларга кешеләр җыела. 1935 елда Иптәш Ленин исемендәге бакча Кызыл Армия йорты карамагына бирелә. Яктырткычлар куела, фонтан кабат ремонтлана, бакчага керү түләүсез була башлый.

1940-1950 еллар башында бакчада түләүле бию мәйданчыгы эшли башлый (керү бәясе – 2 сум). Бу бакча Казан шәһәренең иң популяр урынына әверелә. Аның янында гына ике буфет ачыла. «Комсомолец» кинотеатры эшли.

XX гасырның 50нче елларында коймалар, кассалар урыннарыннан алына, кинотеатр, тир, волейбол мәйданчыклары юкка чыгарыла, радио сөйләми башлый.

1978 елда бөек химик, якташыбыз Бутлеровка һәйкәл куела. 2003-2005 елллардагы ремонт вакытында бакча юлларына брусчатка түшиләр, яшелләндерүне арттыралар.

2004 елның 1 ноябрендә Ленин бакчасының көнбатыш өлешендә Сәяси репрессия корбаннарын искә алу һәйкәле куела. Анда дүрт телдә «Кичер» дип язылган…

Шәһәребездә менә шундый искиткеч бай тарихлы, күп чорлар кичергән бакчаларыбыз бар. Килегез, күрегез.

Нияз БИШБАЛТА,
Казан.

Беркемгә дә кирәкмисеңме?

Үзеңнең беркемгә дә кирәк булмавыңны тою – бик яман хәл. Тормыш кануннарына төшенә генә башлаган сабыйга мондый очракта нишләргә? Өлкәннәрнең, иң кадерле кешеләрнең хыянәтен ничек кичерергә?

Йолдыз ШӘРАПОВА

Соңгы вакытта балалар йортларында тәрбияләнүче ятимнәр саны елдан-ел кими дип, җае чыккан саен мактанырга яратабыз. Әйе, бүгенге көндә республикабызда 11 меңләп ятим сабыйның (моңа социаль ятимнәр дә керә һәм аларның саны күпкә күбрәк тә әле) яңа гаиләсе бар. Язмыш чоңгылына эләккән балаларны уллыкка, кызлыкка алырга теләүчеләр саны да, шөкер, артып тора. Хәтерләсәгез, 2007 елда бу шәфкатьле гамәл массакүләм төс алган иде. Гаиләгә килгән ул сабыйлар үсте, үскән саен, холыклары да үзгәрде. Өметләре акланмаган әти-әниләр үзләрендә тәрбияләнгән ул балаларны кире алуларын сорап мөрәҗәгать итә башлады. Узган елда вакытыннан алда туктатылган мондый килешүләрнең саны 50дән артып киткән. Кире кайтарылганнарның күпчелеге (38) үсмерләр. Ләкин араларында биш яшькә кадәр булган дүрт нарасый да бар. Бу адым, башлыча, әти-әниләр теләге белән эшләнгән, бер очракта гына малай үзе, гариза язып, гаиләдән киткән. Ә бит саннарның һәркайсының артында – аерым бер баланың язмышы. Ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруда, алмаш гаиләләр әзерләүдә ярдәм итүче республика үзәге директоры Светлана Богова белән бу гамәлнең сәбәпләрен ачыкларга тырышабыз.

– Иң беренче сәбәп – әти-әниләрнең чит балаларны тәрбияләргә әзер булмавы, белемнәре җитмәү. Тамырларында үз каның акмаган баланың холкын аңлау җиңел түгел, билгеле. Бала алу кебек тәвәккәл адымны ясарга җыенучылар бүген махсус мәктәп узарга тиеш. 80 сәгатьлек уку курсларында психологлар, юристлар, педагоглар аларны чын-чынлап әти-әни булырга өйрәтәләр. Ә балаларны кире китергән гаиләләрнең бик күбесе мондый мәктәп узмаган, чөнки 2012 елдан башлап кына уку мәҗбүри итеп куелды. Тәрбиягә балаларның күбесе республикада узган Игелек һәм Гаилә елларында (2007-2008) алынган. Аңлашу авырлаша башлагач та кыенлыклар алдында каушап калган өлкәннәр, ул-бу булганчы дип, баланы тизрәк кире китерү ягын карыйлар. Светлана Алексеевна шундый конкрет язмышларга туктала. Алар берсеннән-берсе гыйбрәтле.

Әнә бит Камил белән Наилнең (малайларның исемнәре билгеле сәбәпләр аркасында үзгәртелеп бирелә) әти-әниләре аерылышкач, әниләре тормышның ямен югалта. Балаларына игътибар бирми башлый. Моны күреп торган изге күңелле күршеләр тиешле җиргә хәбәр итәләр. Суыткычында алма белән сөт булмаса да, балаларыңнан колак кагарга мөмкинсең. Монда да шулай була. Ялгызлык кайгысыннан бетәшкән хатын үзенең язмышы белән ризалаша. Югыйсә, кайберәүләр шикелле хәмер белән дә дус булмый. Балалар йортына вакытлыча дип алып кителгән малайларның язмышы шул көннән бөтенләй башка агымга күчә. Хатынны, баларына тиешле тәрбия бирә алмауда гаепләп, ана хокукыннан мәхрүм итәләр. Балалары булмаган гаиләгә эләккән малайлар башта бик бәхетле тоя үзләрен. Әти-әни алар өчен үлеп тора. Ләкин табигатьнең аңлашылып бетмәгән бер кануны бар. Балалары булмаган гаиләләр бала алып беркадәр яшәгәч, еш кына аларның үз сабыйлары дөньяга килә. Күрәсең, ятим сабыйларга биргән назны «күктәге кәнсәләрдә» күреп торып, аларны чын-чынлап әти-әни итәргә карар кылалардыр. Камил белән Наилнең дә кечкенә сеңелләре туа. Озак еллардан соң беренче тапкыр баласын кулына алган яшь ананы аңлавы кыен түгел. Аның малайларга вакыты калмый башлый. Ләкин яшь әни бик акыллы булып чыга. Ул малайларның биологик әниләрен эзли башлый. Һәм таба да. Малайларның үз әниләре инде шактый акыл утырткан була ул чакта. Аңа яңадан ана хокукын кайтаралар һәм ул балаларын үзенә ала. Хәзер Камил белән Наил үз әниләре белән яши һәм кайчандыр үзләрен сыендырган гаилә белән аралашып тора.

СӨЙЛӘШЕП-КИЛЕШЕП

Лилия беренче сыйныфтан бирле сыйныфташы Эльмира белән дус. Бу дуслык елдан-ел ныгый гына бара. Алар инде хәзер бер-берсенә эч серләрен сөйләргә дә курыкмыйлар, кирәк булганда, бер-берсен яклыйлар да. Эльмираның әнисе бердәнбер кызының тәрбиягә алынган бала белән дус булуыннан аны начарлыкка өйрәтер дип тә курыкмый. Яшерен-батырын түгел, күпләрне шул геннар өркетә. Үсә-үсә, кызлар мәктәпкә бергә йөри генә түгел, лагерьларга да бергә бара башлыйлар. Бервакыт лагерьда ял иткәндә, Лилиянең әнисе авырып китә һәм Әниләр көненә килә алмый. Аның каравы, Эльмираның әнисе кызларның икесен дә сыйларлык күчтәнәчләр күтәреп килә. Лилия еш кына, әнисенең рөхсәте белән, ахирәте өендә кунып кала. Аннары үзенең туган көнендә (анда ахирәте әнисе белән килгән була) Лилия күптәнге хыялын әйтә, аның бик тә Эльмиралар гаиләсендә яшисе килә икән. Эшнең шуңа таба барганын сизенгән әнисе дә тавыш чыгармый. Эльмира да әнисен бу уңайдан алдан әзерләп куйган була инде. Ике гаилә дә сөйләшеп, документлар хәстәренә керешә. Берсе килешүне өзә, икенчесе аны башлый.

КЕШЕ СҮЗЕ

Үзләренең сабыйларын югалткач, күңел юанычы булыр дип, алар Коляны кечкенәдән тәрбиягә ала. Малай таза-сау булып үсә. Мәктәпкә укырга кергәч тә, әллә ни мәшәкать китерми. Ләкин көннәрдән бер көнне «яхшы күңелле» бер күршеләре балага әти-әнисенең үзенеке түгеллеген җиткерә. Бу хәбәрдән башлары әйләнеп көчкә кайтып егылган малай, әлеге хәбәрнең дөрес түгеллегенә инанасы килеп, әти-әнисенең күзенә карый. Ләкин алар да сер итеп саклаган хакыйкатьне яшереп кала алмыйлар. Шул мизгелдә малайны алмаштырып куялармыни: өлкәннәрнең сүзен санга сукмый, дорфа сөйләшә, дәрес калдыра башлый. Аннары бөтенләйгә өйдән качып ук китә. Аны аңларга да була. Үзеңнең әти-әни дип яратып яшәгән кадерле кешеләреңнең «хыянәтен» ничек кичермәк кирәк. Аннары үз әнисен табасы килү теләге дә уяна. Ерак авылга улын эзләп килә алмый бит инде ул. Ә менә балалар йортын эзләп табарга мөмкин әле. Өйдә әнисе пешергән коймакны ашап, әтисе машинасына утырып йөрү ничек кенә рәхәт булмасын, үсмер малай балалар йортын сайлый. Икенче тапкыр улларын югалтудан кайгыга баткан ата-анага килешүләрен вакытыннан алда өзүдән башка чара калмый.

ҖАН ТАРТМАСА, КАН ТАРТА

Светлана ханым һәр баланың язмышын үз йөрәге аша уздырып сөйли дә сөйли…

Балаларны кире тапшыру очракларының сәбәпләре болар гына түгел, билгеле. Ятим калган оныкларын кызганып, үз канатлары астына алган әби-бабайларның да еллар үткән саен аларны тәрбияләргә көч-егәрләре, теләкләре калмый башлый. Кире кайтарылган балалар саны алар хисабына да арта. Аннары мәктәп тә мондый балаларны һәм гаиләләрне бик аңларга атлыгып тормый. Мәктәптә булган теләсә нинди кыек эшне шул сабыйдан күрә башлыйлар. Еш кына ак эт бәласе кара эткә эләгә. Ике ут арасында калган ата-ана нишләсен, авыртмаган башка тимер тарак булды бала дип, аңардан вакытында котылырга теләп, кире алуларын сорап гариза яза.

Ярый инде, әлеге республика үзәге психологларының вакытында күрсәтелгән ярдәме белән, кайбер балаларны яңа гаиләләрендә яшәтеп калдырып була. Билгеле, бу ике яктан да зур тырышлык, сабырлык сорый, ләкин бала язмышы хакына барысын да эшләргә әзер алар. Хәзер инде бу проблеманы урыннарда хәл итәр өчен махсус комиссияләр дә төзелгән. Килешүне өзгәнче, алар бөтенесен дә җентекләп тикшерәләр: мәктәп, өстәмә белем бирү учреждениеләре, балигъ булмаганнар комиссиясе ни эшләгән – барысы да энә күзеннән үткәрелә. Әгәр чынлап та балага гаиләдә рәхәт түгел, ике як та үз фикерен генә алга сөрә башлаган икән, билгеле инде, килешүне вакытыннан алда өзәргә туры килә.

– Мин үзем һөнәри әти-әниләрдән торган гаиләләр ягында. Безнең үзәктә аларны махсус укыттык. Болар – бу мәсьәләдә тәҗрибәле кешеләр. Аларга тәүлекнең теләсә кайсы вакытында ярдәмгә мохтаҗ сабыйны кертеп, гаиләле итеп була. Ятимнәрнең киләчәген шулар кулында күрәм. Алар үзләре өчен түгел, балалар бәхете өчен яшәүчеләр, – дип, аңгәмәбезгә кушылды үзәкнең директор урынбасары Ксения Трушкова.

Аның белән килешми мөмкин түгел. Соңгы арада ватсап (вәт шәп!) модага кереп китте бит. Тәрбиягә бала алучыларның үз төркеме бар анда. Шунда язылган фикерләрне сезгә дә җиткерәсем килә. «Бер генә бала да дөньяга гариза язып, үзе теләп килми. Алардан берни дә таләп итәргә кирәкми. Без, өлкәннәр, аларга бу дөньяда яшәргә булышырга тиеш. Балаларга канатлар һәм тамырлар бирергә кирәк. Канатлар – биегрәк очар, ә тамырлар һәрвакыт әйләнеп кайтырга урын булсын өчен.»

Әлфия Ильясова белән Наталья Николаева.

Автор фотолары

СӘНГАТЬ ӘХРАМЫ

«Күчеп йөрүче ХӘБӘР»ләр «Шәһри Казан»да

Татарстан рәссамы Әлфия Ильясова белән Якутиядән килгән Наталья Николаева моннан 12 ел элек Төркиядә ТЮРКСОЙ халыкара төрки мәдәният оешмасы оештырган иҗат лабораториясендә дуслашалар. Хәер, бу икәве генә түгел, аларның 14 рәссамнан торган иҗат төркеменең дуслыгына хәтта кураторлар үзләре дә игътибар итми калмый. Менә шуңа да, аерылышканда, дуслыкны сакларга, иҗади элемтәләрне югалтмаска дип сүз куеша алар. Бер урынннан икенчесенә күчеп йөри торган күргәзмә проектын Наталья белән Әлфия нәкъ шул максатны күздә тотып тәкъдим итә дә. Әмма кай яклап карасаң да, рәссам өчен теләсә кайсы күргәзмә шактый гына чыгымнар таләп итә. Эшләрне рамлатудан алып, транспорт чарасына кадәр исәпләсәң, ярыйсы гына түгәрәк сан килеп чыга.

Расиха ФӘИЗОВА

Шуңа да кызлар төркемдәшләре – Кыргызстанның халык рәссамы, сынлы сәнгать профессоры Юристанбәк Шыгаевның тәҗрибәсен нигез итеп алалар. Чөнки аның ни рәвешле эшләвен һәм бу алымның чыннан да кулай булуына алар үз күзләре белән күреп инаналар.

– Менә мин дөнья буйлап күргәзмәләр ясап йөрим, бер дә рам дип матавыкланганым юк. 40-50 картинаны контейнер белән поездда, самолетта йөртә башласаң, беренчедән, бик уңайсыз, икенчедән, адым саен артып киткән килограммнар өчен түли башласаң – кыйммәт. Әнә бит безнең борынгы бабаларыбыз бер җирдән икенчесенә күченеп йөргәндә, бөтен әйберләре ат өстендә булган. Йортларын да төреп алып теләсә кая күчереп йөрткәннәр. Мин дә бөтен эшләремне менә шулай көпшә сыман итеп төрәм дә (свиток) чыгып китәм, – ди Юристанбәк Шыгаев аларга, үз тәҗрибәсе белән уртаклашып.

Шул рәвешле, булачак проектның башкару технологиясе дә хәл ителә. Башкаларга ирештерәсе килгән хәбәрен рәссамнар 1х3 яки 1х5 метр зурлыгындагы киндердә башкарырга һәм свиток рәвешендә җибәрергә тиеш дигән карарга киләләр. Җитмәсә төргәкләр почта аша йөртү өчен дә бик кулай булып чыга.

Башта проектта ТЮРКСОЙда катнашкан 14 рәссам гына катнашыр дип гөманлыйлар. Аның зур бер халыкара проектка әвереләчәге башларына да килми. Иң беренче күргәзмә 2006 елда Мәскәүдә Милләтләр йортында III этноартфестиваль кысаларында уза. Шул чакта галерея директоры Башкортстан кызы Наталья Батырова проект турында Уфада яшәүче рәссам Васил Ханнановка хәбәр итә. Шулай итеп, идеяне Башкортстандагы татар рәссамнары да күтәреп ала.

– Гомумән, 90нчы елларда СССР таркалгач, без – элеккеге союздаш республикалардагы рәссамнар – бер-беребезне юксына башладык. Аралашуга мохтаҗлык бар, чөнки иҗади багланышлар безне профессиональ яктан үстерә. Шуңа күрә проекта шигарьне дә «Край мәдәниятеннән – дөнья мәдәниятенә» дип куйдык, – ди Әлфия Ильясова.

Тора-бара проектның географиясе шул кадәр киңәя ки, хәтта Уфада, Мәскәүдә, Чиләбедә, Оренбурда, Удмуртиядә, Төрекмәнстанда төбәк кураторлары барлыкка килә. Казанда исә бу эшне Мәдәният министрлыгыннан халыкара мөнәсәбәтләр бүлеге җитәкчесе Рәйсә Сафиуллина, ә Чаллыда рәссам Хәмзә Шәрипов алып бара. Проектка исемне исә мәрхүм Наил Байбурин (Башкортстан) тәкъдим итә.

Исеменә күрә җисеме дигәндәй, юл йөрүдән бер дә туктамый әлеге проект. 2007 елның апрелендә «Күчеп йөрүче ХӘБӘР»ләр белән казанлылар да таныша. «Кочующие свитки. Kazan-Habar» дип аталган каталог дөнья күрә. Рәссамнар берлегенең күргәзмәләр залында узган ачылу тантанасында проект авторлары Әлфия Ильясова белән Наталья Николаевага ТЮРКСОЙның мактаулы билгесе тапшырыла. Шул ук елның ноябрендә «хәбәрле төргәкләр» Уфага, аннан Әнкарага (Төркия) китә. Күргәзмә Яңа Шәһәрдә,Татарстан Республикасы көннәре кысаларында Истанбулда да эшли.

– 2008 елда проектның туплануы Якутиядә бернича мәйданда күрсәтелде. Аннан Ижевск шәһәрендә ике урында – Сынлы сәнгать музеенда һәм Ижевск сәнгать университетында күргәзмәләр узды. Бер елдан аларны кабат Мәскәү тамашачысына тәкъдим иттек. Бөтенроссия кулланма-гамәли һәм халык сәнгате музеенда узды ул вакытта күргәзмәләр. 2015 елда Пермьдә узган KAMVA Халыкара этнофутуристик фестивалендә дә тәкъдим иттек эшләрне, – дип, проект узган юлны барлый рәссам Әлфия Ильясова.

Әле боларга өстәп, әлеге эшләрнең «Сәнгать паркы» проекты кысаларында янә Казанда, Аксубайда, Актаныштa күрсәтелүен; Болактагы театрда «төргәкле хәбәр»ләрнең «Казанское сокровище» спектаклендә декорация буларак файдаланылуын, күргәзмәләр барышында барлыгы дүрт каталог чыгуын да өстәргә булыр иде. Шул дәвер эчендә проектка барлыгы 150ләп рәссам кушылып, Татарстан, Саха-Якутия, Башкортстан, Мари Эл, Чувашия, Мордовия, Удмуртия, Коми, Молдова (Гагаузия), Кыргызстан, Казахстан, Төрекмәнстан, Төркиядән 300гә якын эш кабул ителә.

– Инде тәҗрибәдән чыгып әйтә алам, бу проектка битараф калу мөмкин түгел. Ул безне дә, рәссамнарны да якынайтты. Рәссамнар өчен файдалы, тансык иҗат лабораториясе булды. Тукайның 120 еллыгын билгеләп узганда, Татарстан рәссамнары әлеге форматны («УрманАРТ»ы проекты) бик теләп файдаландылар. Форма белән эчтәлекнең тәңгәл килүеннән отты бу проект, – ди Рәйсә Сафиуллина.

Яхшы үрнәкне эләктереп алырга гына торуларын тагын бер кат раслый әлеге проект. Әйтик, әнә Якутиядә «Күчеп йөрүче ХӘБӘР»дән аерылып чыгып, үзләре өр-яңа «Кочующие свитки Сибири» булдырганнар. Эшләрен инде Бельгия, Франция, Польшада күрсәтергә дә өлгергәннәр.

– Проектның икенче этабын игълан итәргә вакыт җитте. Без бу мәсьәләне онлайн киңәшмә вакытында да күтәреп чыктык. Яңа этап «Евразия» дип аталачак һәм без Себернең «Күчеп йөрүче хәбәр»ләре белән Евразиядә очрашачакбыз, – диләр проект авторлары.

Әлегә проектка кергән эшләрнең бер өлеше белән хәзерге вакытта «Шәһри Казан» редакциясенең күргәзмәләр залында танышырга була.



мәдәният

Аны «Мансур» дип каршы алалар

Әлмәт Татар дәүләт театрының яшь артисты Динар Хәснетдинов тамашачы күңеленә «Ак чәчәкләр» фильмы аша кереп калды. Бүген ул – безнең кунагыбыз.

– Динар, син сәхнәгә очраклы гына килеп эләккән кеше түгелсеңдер? Ничегрәк булды ул?

– Балачактан ук сәнгатькә мәхәббәтне әни тәрбияләде. Без ике малай әни белән генә үстек. Әле дә хәтеремдә, ул миңа Муса Җәлилнең «Күршеләр»ен ятлаткан иде. Бүгенгәчә шул исемнән чыкмый. Мәктәптә укыганда ук әни мине төрле конкурсларга йөртте. Үзе дә яшь чагында сәнгать юлыннан китәргә хыялланган булган. Мине Чаллыдагы театр мәктәбенә бирүе дә юкка булмагандыр. «Их, артист булсаң иде син», – дип әйткән сүзе әле дә истә. Әни үлгәндә, үнөч яшь иде миңа. Әнинең хыялын тормышка ашырырга тиешмен, дип, үз алдыма максат куйдым. Шуңа күрә 11нче сыйныфтан соң Казан театр училищесына укырга киттем. Ул елны Әлмәт театры өчен махсус курс җыйдылар. Шунда имтихан биргәндә үк театрның директоры Фәридә Исмәгыйлева яныма килде дә: «Динар, әгәр дә Әлмәткә эшкә кайтасы булсаң, сиңа стипендия түләп укытачакбыз», – диде. Мин каршы килмәдем. Училищеда Илдар Хәйруллинда укуым белән горурланам. Әлмәт театрына өч елга дип килгән идем, инде алтынчы ел эшлим. Театр дөньясына бер кереп китсәң, тиз генә чыгып булмый икән.

– Беренче адымнарыңнан ук үзеңә бәхет елмайды дип әйтә аласыңмы?

– Әлбәттә. Бәхетне тоя белергә кирәк. Аллага шөкер, кул-аягым исән-сау. Эшемне яратам. Пензада узган «Безнең заман герое. Актер» номинациясендә, Самарадагы «Волга театральная» фестивалендә «Икенче пландагы ир-ат ролен иң яхшы башкаручы» төрендә җиңү яулап кайтуларым сөендерде. Алкышларга куанып, тамашачы игътибарын тоеп яшәүне мин бәхет дип саныйм. Читтә уңышка ирешү кыйммәтрәк тә әле, чөнки анда сине белмәгән тәнкыйтьчеләр бәяли.

– Рольләрең арасында «Балакаем» спектаклендә наркоман егет тә бар.

– Үземчә аны бик тырышып уйнадым. Абыем исә, спектакльне караганнан соң, төне буе саташып чыккан иде. Күңеленә бик авыр кабул итте ул аны. Икенче яктан, минем иң таләпчән тәнкыйтьчем дә абыем.

– Әгәр Казанга берәр театрга чакырсалар, килер идеңме?

– Чакырулар еш була. Әмма мин беркайчан да үз алдыма планнар корып яшәмим. Бүгенге көнемнән канәгатьмен. Башымны югалтып, акча артыннан кумыйм. Булганына шөкер итеп яшим.

– «Ак чәчәкләр» фильмнан соң үзеңә гыйшык тотып йөргән кызлар да булмый калмагандыр...

– Кызлар язган сүзләргә бик бирешмәскә тырышам, чөнки алар мине үзләренчә идеаллаштыралар. Алар бит миңа түгел, образыма гашыйк була. Казан сәхнәсенә чыккач та: «Әнә Мансур», – дип каршы алалар. Интернетта кайбер хатын-кызлар «Улым булсаң иде» дип тә язалар. Миңа бик күңелле булып китә.

– Сәхнәдә кызларның күңелен яулаган егетнең насыйп яры нинди булырга тиеш?

– Ике арада мәхәббәт булырга тиеш. Әгәр син аны яратсаң, аның начар сыйфатлары да яхшы булып күренә. Шуңа күрә дә ниндидер сыйфатларны аерып әйтә алмыйм.

– Саф мәхәббәт турындагы тагын кайсы спектакльләрдә үзеңнең күңеленә якын булган рольләреңне атый аласың?

– Мин Чаллы театрының спектакльләрен карап үстем. «Гашыйклар тавы» спектакле күңелгә шундый кереп калды. Сәет ролендә уйнаган Рафил Сәгъдуллинның монологын ятлап, үзенә дә сөйләп күрсәткән идем. Театр училищесына да шуны сөйләп кердем. Аның әнтәлеге дә минем тормышыма тәңгәл килә. Сәет тә әнисен югалта. Мин ул монологны хәзер дә сәхнәдә сөйлим.

– Динар, әниең гел теләкләрең төшми...

– Мин һәрвакыт әнинең ярдәмен сизгән кебек. Әгәр әни исән булса, без Казанда яшәр идек, әнине эшләтмәс идек дип уйлыйм. Ул безнең өчен тырышты. Аның тормышы җиңел булмаган. Мәскәүдән товар ташып, базарда сату итте. Тормышта рәхәт мизгелләр кичерә алмый калды. Әбиебез әле дә исән-сау, ул минем Чаллыга кайтуымны көтеп ала.

«Театрда икенче дөньяга кереп китәсең»

Дәрвишләр бистәсендәге Сәетгалиев исемендәге мәдәният сараенда эшләп килүче халык театрына – 70 ел. Аның тарихы сугыштан соңгы авыр еллар-да башлана.

Казан оптика-механика заводында эшләгән яшьләр җырлап-биеп күңел ачарга яраталар. Алар җор телле Габдрахман Җиһаншин янына тупланып спектакльләр куя башлыйлар. Заманында коллектив белән Әнвәр Гобәйдуллин, Мөхтәр Әхмәдиев җитәкчелек итә. 1959 елда Сәетгалиев исемендәге мәдәният сарае ачылганнан соң, Камал театры анда «Кыз урлау» спектаклен куярга килә. Котләхмәт ролен Татарстанның халык артисты Һидият Солтанов башкара. Спектакльдән соң үзешчәннәр аның янына кереп, үзләрендә театр түгәрәген җитәкләргә тәкъдим итәләр. Ул куйган «Шәмсекамәр» спектакле белән халык театрлары конкурсында лауреат исеме алалар. Коллективка халык театры исеме бирелә. Һидият Солтанов 22 ел эшләп киткәч, коллективны Шамил Галиуллин, Билал Гайнуллин җитәкли. 2008 елдан бирегә Рафис Фазылҗанов килә. Ул коллективның уңышлары белән горурлана.

– 70 ел эчендә труппада 120дән артык егет һәм кыз уйнаган. «Хаҗи әфәнде өйләнә» спектакле унбиш ел буе сәхнәдән төшмәгән. Коллектив спектакльләрне Казанда гына күрсәтеп калмыйча, гастрольләргә дә йөри. Ул хәзер дә шулай. Фестивальләрдә төрле номинацияләрдә җиңүләр яулау тагын да илһамланып эшләргә этәргеч бирә. Бүгенге көндә труппада 15 артист. Ул яктан бераз кытлык кичерәбез. Сәләте булган кеше безгә килеп үзен сынап карый ала. Без тамашачыны да тәрбиялибез. Әгәр халык театры булмаса, Камал, Тинчурин исемендәге театрларга кем йөрер? – ди режиссер.

Рафис бер вакыйганы искә төшереп узды. Казанның уртасында салынган Мулланур Вахитов һәйкәлен эшләгәндә, сынчы революционерның йөзен әлеге коллективны җитәкләгән һәм Мулланур Вахитов ролендә уйнаган Билал Гайнуллинга карап ясаган.

Гүзәл Шакирова моннан өч ел элек Алабуга шәһәреннән күченеп килгәч тә әлеге халык театрын эзләп табып, анда йөри башлаган. Кайчандыр университет тәмамлап, Актаныш районында эшләгәндә Сәфәр, Татар Суксуы авылларында театр түгәрәген җитәкләгән. Биредә күңеленә ятышлы коллективны табуына сөенеп туймый Гүзәл.

Зилә Идрисова белеме буенча педагог. Беренче мәртәбә театр репетицияләрен шаккатып карап тора. Аннары үзе дә шушында йөри башлый. Бигрәк тә аны режиссер Шамил Галиуллин җәлеп итә. Торгынлык чорларында алар коллективны саклап калалар.

– Театрда яшь чакта кызык өчен уйныйсың. Ә хәзер үзебезнең арттан яшьләрне тартасы килә, – ди Зилә ханым.

Труппадагы яшь артистларның берсе Алсу Мифтахетдинованы да Зилә ханым алып килгән. Ә иң өлкән артист – Илсур Фәйзуллин чирек гасыр буе шушы коллективта төп рольләрдә уйнаган. Аның әйтүенчә, спектакльдә уйный башлау белән, икенче дөньяга кереп китәсең. Уңай образмы, тискәреме, аның тәрбияви роле мөһим. Илсур әфәнде Зиннур Сәйфетдинов, Ильяс Гайнуллин, Рәфыйк Мингалиев кебек элекке артистларны да искә алды.

Мәдәният министрлыгы «Бөек илнең мәдәни мирасын саклыйбыз» дигән Бөтенроссия смотр-конкурсы уздыра. Ул Россия халыкларының милли-мәдәни байлыгын саклау һәм популярлаштыру максатыннан үткәрелә.

Мәдәни мирасны саклыйбыз

Бәйгедә мәктәп һәм балалар бакчаларыннан аерым башкаручылар һәм иҗади коллективлар, милли, халык коллективлары, мәдәният йортлары һәм башка оешма каршындагы иҗади коллективлар катнаша ала.

Сайлап алу комиссиясенә милли җырлар, биюләр, шигъри әсәрләр башкарып яздырылган видеотасма җибәрергә кирәк. Гаризалар 10 апрельгә кадәр кабул ителә. Эшләрне оештыру комитетының электрон почтасына җибәрергә яки «Сохраняем культурное наследие великой страны» (www.сохраняем-наследие.рф) сайтына куярга кирәк.

17 апрельдән эшләрне тавыш бирү юлы белән халык үзе бәяли башлаячак. Иң яхшы дип табылганнар конкурс иганәчеләренең бүләгенә һәм дипломнарга ия булачак.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА әзерләде.

КЕШЕ ҺӘМ ХОКУК

Астыртын гамәлләрнең гаугасы зур

Татарстанда хакимият органнарында монополиягә каршы законнарны бозу очраклары сизлерлек кими башлаган.

– Хакимият органнарында һәм җирле үзидарәләрдә 2015 елда 225 очрак теркәлгән иде, узган ел алар 62 генә булды, – диде Россиянең монополиягә каршы федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Рузалин Хәбибуллин «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында узган матбугат конференциясендә.

Ләкин, хакимият органнары хезмәткәрләре монополиягә каршы законны төгәл үтәүгә керешкәннәр, дигән сүз түгел әле бу. Көндәшлеккә юл куймау, аукционнарны дөрес үткәрмәү, җир мөнәсәбәтләренә һәм хезмәт күрсәтүләргә кагылышлы хаталары өчен Чаллы шәһәре үзидарә органнарына – 48, Казанга – 36, Югары Ослан муниципаль районына – 34, Биектау муниципаль районына – 25 һәм Питрәч муниципаль районына 21 кисәтү бирелгән.

– Узган ел монополиягә каршы законнарны бозганнары өчен 197 җитәкчегә һәм юридик затка административ эш кузгатылды. Аларга 6 936 мең сум штраф салынды. Монополиягә каршы законнарны бозганнары өчен юридик затлар гомуми исәптә 9 981 400 сум штрафка тартылды. Шуның 1 388 363,3 сумы инде түләттерелде, – диде Рузалин Хәбибуллин.

Тукай, Биектау, Югары Ослан муниципаль районнары җылылык һәм су белән тәэмин итү корылмаларын тапшыруда закон таләпләрен төгәл үтәмәгән. Питрәч, Кайбыч, Югары Ослан, Спас муниципаль районнарында реклама корылмаларын урнаштыру схемасы расланмаган. Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә, Югары Ослан һәм Алабуга муниципаль районнарында, көндәшлек мөмкинлеге булуга карамастан, муниципаль унитар предприятие оештырганнар.

Аукцион үткәрү тәртибенә, аның нәтиҗәләренә ризасызлык белдерелгән 861 гариза кергән. Шуларның 80 процентында законнарны бозу факты ачыкланган.

– Аукционнарда, гадәттә, документлаштыруда хаталар күзәтелә, беркетмәләр тиешле срокта игълан ителми, – дип аңлатты Рузалин Хәбибуллин. – Җир кишәрлекләре сатуда закон бозулар еш очрый. Җир кишәрлеге сатылу турында районнардагы рус һәм татар телләрендәге газеталарның икесендә дә алдан ук хәбәр ителергә тиеш.

Кайбер иминият компанияләрендә автогражданлык җаваплылыгы полисындагы графага автокурсларны яңа тәмамлаган яки транспорт чарасын идарә итү стажы берничә ел гына булган кешене өстәп язудан баш тарталар икән. Димәк, ОСАГО полисында фамилиян язылмаса, син транспорт чарасын идарә итә алмыйсың. Рузалин Хәбибуллин: «Иминият компанияләре баш тартырга тиеш түгел, бу – законны бозу», – дип әйтте.

Дамир БӘДРИЕВ.

ПОЧТАДАН

Очрашу урыны – китапханә

Компьютер-телефон кебек замана җайланмалары күп төрле уңайлыклар тудыра тудыруын, әмма кешеләрнең элеккеге кебек утырмага җыелып аралашуларына берни дә җитми икән.

Яшел Үзәндәге Фаил Шәфигуллин исемендәге китапханәдә үткән үзенчәлекле очрашу һәркемдә дә күркәм тәэсир калдырды дип әйтсәк, һич кенә дә арттыру булмас. Ак шәл бәйләгән өлкән яшьтәге мөхтәрәм әбиләребез оештырды аны. Нәкъ үзебезчә кул биреп күрешеп, йөзгә-йөз карашып, ашыкмыйча гына хәл-әхвәлләр белешүдән башланып китте кичә. Аулак өй дип атадылар аны һәм башта үзләренең яшь чагындагы утырмаларын искә төшерделәр. Аннары җырларга, уймак салып уйнарга керештеләр. Әлбәттә, кул эшләре дә алып килгәннәр иде. Кем йон эрләде, кем бәйләде, кем чигү чикте. Шөгылен дә, уенын да оста үтәделәр үзләре. Бер нәрсәне дә онытмаганнар, сөбханаллаһ!

Китапханә хезмәткәрләре дә кул кушырып утырмады: Фәния Хәкимова һәм Наилә Хәсәнова башкарган милли биюләр кичәне төрләндерде, аңа ямь өстәде. Очрашуны мәктәп балалары да тамаша кылды. Алар янәшәдәге 16нчы һәм 19нчы мәктәпләрдән килгән иде. Уңды укучылар ул көнне. Әбиләренең яшьлек хатирәләрен һәм моңлы җырларын тыңлап кинәнде алар. Милләтебезнең гореф-гадәтләрен менә шулай үз күзләре белән күрергә җай чыкты балаларга.

Гаҗәп, аулак өй тәмамлангач та тамашачы, тансык рәхәттән аерыласы килмәгән шикелле, таралырга ашыкмады. Бөтенесе дә бередә күргән-ишеткәннәреннән канәгать калуларын белдерергә теләде. Халык күңелендә сакланган менә шундый гади генә чара да шау-шулы һәм ыгы-зыгылы тормышта талган күңелләрне юата ала икән.

Шәмси ГАЛИЕВ,
Яшел Үзән.

Телевидениедән татарча тапшыруларны аз караударының төп сәбәбе итеп, кайбер дикторларның туган телебездә матур сөйләшә белмәүләрен аерып күрсәтүчеләр шактый. Ләкин киләчәктә бу проблема калмас дип ышанырга тулы җирлек бар. Без бу эшкә үзебез кулдан килгән кадәр ярдәм итәргә булдык.

Бүгеннән киләчәкне кайгыртып

«Сәләтле буын» шәһәр бәйгесе шушы максатны күздә тотып оештырыла. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитетының Казан бүлеге, «Татарстан – Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясенең «Яшь ТНВ» телеканалы һәм без «Елга аръягы» балаларга өстәмә белем бирү үзәге бергәләп оештырдык аны. Ике этапта узган бәйгедә Казанның татар телен яхшы белгән 1-11нче сыйныф укучылары катнашты. Беренче этап – сайлап алу, икенчесе – финал ярышлары. Яшь үзенчәлекләренә карап, балалар өч төркемгә бүленеп чыгыш ясадылар. «Танышу» мәйданында катнашучылар үзләре турында сөйләделәр, яраткан әсәрләреннән өзекне «Әдәби галәм» бүлегендә тәкъдим иттеләр. Алып баручы роленда дә булдылар. «Каләм, кальбеңдә ни бар?» номинациясендә үзләре иҗат иткән шигырь, хикәя, эссе, әкиятне сөйләп күрсәттеләр, таныш булмаган тексттан хата эзләделәр, интервью остасы икәнлекләрен дә исбатларга тырыштылар.

Бәйгедә катнашучы балалар чыгышын республикабызның танылган сәнгать әһелләре, телевидение журналистлары, педагоглар бәяләде. Жюрида булган Татарстанның халык артисты, Кәрим Тинчурин исемендәге театр артисты Илгизәр Хәсәнов, «Яшь ТНВ» телевидениесенең тапшырулар редакторы Роза Әдиятуллина, күп еллар филармониядә нәфис сүз жанрында эшләгән Зифа Гәрәева, балалар шагыйрәсе Йолдыз Шәраповаларга конкурсантларның чыгышын бәяләү җиңел булмады. Чөнки һәрбер укучы, укытучы, хәтта әти-әниләр, әби-бабайлар да бу бәйгегә бик җитди карап әзерләнгәннәр иде. Бәйгенең җиңүчеләре күп булса да, җиңелүчеләре булмады. Балалар телебезнең бөтен матурлыгын, аһәңен башкаларга да аңлатырга тырыштылар.

Мәдинә ХӘЙРУЛЛИНА,
Киров районы «Елга аръягы» балаларга өстәмә белем бирү үзәгенең милли бүлек җитәкчесе.

Әти атларны бүредән коткарган

Еш кына әти сөйләгән истәлекләрне барлап утырам. Әтием Идиятулла хәзерге Әлки районы Төгәлбай авылында 1985-1973 елларда яшәде. Ул Бөек Октябрь революциясендә дә катнашкан.

Аның әти-әнисе Шакир бабай белән Миңҗамал әбинең җиде балалары була. 1916 елда әти күршедәге Сабир абый белән патша армиясенә чакырыла. Әстерхан якларында хезмәт итәләр. 1917 елда революция башлангач, патша власте тар-мар ителә. Әти сөйләгәнчә, бәрелешләрнең берсендә аклар армиясен кызыллар гаскәре чорнап ала. «Бирелергә теләмәсәгез, баржага төяп, Тәркиягә озатабыз», – диләр. Шул чакта меңләгән кеше баржага төялә. Кызганыч, бер тозак була бу. Әти дә, Сабир абый да бер төркем халык белән ярда кала. Баржаны хәрби катер 100 метрлы трос белән диңгезгә сөйрәп керә дә, ярдан ике чакрым тирәсе ераклашкач, ычкындыра. Баржага туптан аталар. Меңләгән кеше аянычлы төстә су төбенә китеп һәлак була. Шул вакыт ярда калган халык кызыллар армиясенә күчә. Алар 1920 елларга кадәр Кавказ, Урта Азия якларында Совет власте урнаштыру эшләрендә катнашалар. Командирлары Якуб Чанышев, Михаил Фрунзе җитәкчелегендә шактый күп бәрелешләрдә катнашалар. Солдатларга бары 1921 елда гына туган якларына кайтырга рөхсәт була. Идел буенда ул чакта ачлык еллары. Әти белән Сабир абый читтән дүртәр пот ризык алып кайталар: кипкән балык, җимешләр, төрле ярмалар. Идел буендагы пристаньнан аларны Шакир, Хөснетдин бабайлар атлар белән каршы ала.

Хәрби хезмәттән кайткан егеткә кызларның да күзе төшә. Тик әтинең армиягә киткәнче үк яраткан кызы – Тәҗелнисасы була. 1922 елда алар гаилә коралар. Җиде балалары туа. Кызганыч, апам Зәмзәмия, абыем Хәсән бала чакта ук вафат була. Әтинең озак вакыт «Кызылармеец» колхозына ат белән ягулык ташыганы истә. Соңрак ат караучы булып та эшләде. Атларны көтүкәндә булган бер вакыйганы гел сөйли иде әти мәрхүм. Тайларны ашамакчы булып, өч бүре һөҗүм итә аларга. Әти исә бүреләрне сыртына чукмарлы таягы белән кундыра. Шулай да берсе аягын тешләргә өлгерә. Атлар исән, бүреләр ач кала. Әти бер айлап аягындагы яраны дәвалады. Әтинең кыюлыгын бәяләп, колхоз идарәсе бер пот бодай һәм өч кило бал биргән иде.

Әтинең сабырлыгы, тыйнаклыгы, батырлыгы минем өчен бүген дә үрнәк. Балаларыннан исән калганы бүген бер мин генә. Үзем дә 81 яшемне тутырдым инде. Әтиәниемне искә алуым аларның рухларына дога булып ирешсен.

Сөләйман ШАКИРОВ,
Казан.

ХИКӘЯ

→ Дәвамы. Башы 3 март санында.

КАЗ КАНАТЫ

Лүзия САЛИХОВА

Имеш, каз бәпкәләре белән елгага төшкәннәр, иртәнге кояш нурлары җем-җем ялтыраган суда салмак кына йөзеп йөриләр. Бәләкәй әбинең йорты авыл башында күперне чыккач та булганга, ничә еллар инде салкын сулы елганы беренче булып сәламләүче кара әнкә каз иде. Суга иелгән нәфис талларга, ак кубектәй ак чәчкәдәге шомыртларга сокланып, сандугач сайравына хисләнеп тә йөзә иде; көзге сары яфраклар су өстенә коелганда да, яр буйлары ак кар белән капланганда да, юка гына челтәр бозны сак атлап үтеп, рәхәтләнеп юына-коена. Чумып-йөзеп хушлангач, яңа яуган саф кар өстендә кызыл тәпиләре белән эз сала-сала, хуҗабикәсе янына ашыга иде. Кайда калды ул бәхетле мизгелләр? Татлы төштә, хыялдамы?... Каз уянып сискәнеп куйды. Үрдәк бәпкәләрен дус иткәннән бирле утырып түгел, аягүрә дә черем иткәне булмаган ич, ә монда көндезен йоклап утыр инде! Алай дисәң, көн кичкә авышкан, офык тирәли агылган күгелҗем болытлардан яңгыр исе килә. Ә елгада коенмаганга күпме гомер узган? Яздан бирле бугай инде. Каз, каерылып, елга буен күзләде дә, салмак кына басып, елгага юнәлде. Су юлы сагындырган икән, адымнарын тизләтте. Яр буена килеп җитүгә, әрнеп янган күкрәген суга тидерде, нәзәкатьле итеп бер-ике тамчы су йотып куйды, йөзеп китте. Менә кайда икән ул җәннәт! Баш әйләндергеч җиңеллек! Әй тереклек патшасы, галиҗәнап су! Синең кочагыңда бар хәсрәтләр, ару-талулар югала, дәрт уяна. Бетмә, дөнья, сүнмә, тормыш: мәңге-мәңге яшисе килә. Каз агымга каршы йөзеп китте, аксын-китсен, онытылсын үткәннәр, тыныч-рәхәт киләчәк булсын.

Су уртасында ялгыз гына йөзгән казның каурыйларын кузгатып көчле җил исеп үтте,ялтырап, яшен яшьнәде,бераздан күк күкрәве ишетелде. Су өсте дулкынланды, казны як-якка чайкады. Әмма казның җилдә дә, яшендә дә эше юк: бөтен игътибары туган йорты – Бәләкәй әби йортында иде.

Әби, капкасын ачып куеп, көтүдән кайтучы сыерын каршыларга әзерләнде. Ишегалдының һәр почмагында аның ак яулыгы балкып-күренеп алды. Җиңел хәрәкәтле җитез-уңган әби мал-туарын барлый, бүгенге көнне тәмамлап, иртәгәсенә әзерләнә.

«Ничек кайтыйм да ничек күзенә күреним?» Каз кошлар нәселеннән булса да, оят дигән төшенчәне аңлый иде, мөгаен, кеше нәселеннән булганнар өчен дә җаваплы сыман иде. Зифа әби янына кайта алмаячагын уйлады. «Кемгә кирәк мин хәзер, ни файдам бар әбигә? Күз көеге булып яшәргәме... Гөнаһсыз үрдәк бәпкәләре...»

– Ли-ли-ли!

Капка ягыннан әби тавышы яңгырады. Каз йорты ягына талпынып куйды да, исенә килгәндәй, тал ышыгына яшеренде. Юк,әйләнеп кайтулар булмас инде.

Ул, яраткан әбисенең алсу күлмәкле, ак алъяпкычлы җыйнак гәүдәсен күрмәс өчен, башын канат астына яшерде, өзелеп чакырган кадерле тавышка колак салмаска тырышты. Күңел газабына түшенең авыртып сызлавы да кушылды. Калын үкчәдән калган ярадан әкрен генә кан саркый иде. Яра, суга тигәч, тагы да зураеп киткәндәй булды, су әрнүне баса төшсә дә, каз хәлсезләнә барды.Тал ышыгында су өстендә төн чыгу иде казның нияте. Ул язмышка буйсынырга уйлады.



Зифа әби, каз-үрдәкләрне эзләп-эзләп тә тапмагач, тәмам аптырашка калды. Күршесе янына кереп чыкты. Анысы көне буе урманда булган икән, шәһәрдән кайткан балалары белән печән әзерләргә барганнар. Бәләкәй әби дә әрәмәдән кояш баеганда гына кайткан иде, чапкан печәннәрен киптереп чүмәләгә куйгач кына. Ни тырышты яңгырга чаклы җыештырыйм дип, ә яңгыр дигәнең яумады. Йа Ходам, үзеңә тапшырдым, дип, Бәләкәй әби башын түшәккә салды. Арыганлык үзенекен итте, күзләрен йокы басты. Ачык тәрәзәдән кергән дымлы яңгыр исе әбине бишектәгедәй тибрәтте, мич астындагы моңлы чикерткә бердәнбер җырын сузды, йомшак ак песие аяк очына урнашты. «Йа Раббым...» Әби дога пышылдаган рәвештә сабый баладай изрәп китте, әмма бик кыска булды аның татлы йокысы. Бераздан әби шомланып уянды: «Казым кайтмадымы икән?» Догаларын ишетелер-ишетелмәс кенә укып ишектән чыкты да, төнге салкынча һаваны сулап, капкага таба атлады. Тып-тын. Төн караңгы, болытлы, еракта аҗаган уйный. Бар җиһаннан җәй исе – чапкан мәтрүшкәле печән, каен яфрагы, җиләк исе килә. Бөтенесе: караңгылык, тынгысызлык, салкын сабырлык бергә катнашкан. Күңелдә хисләр өермәсе, уйлар...

Ничә еллар үтсә дә, иң кадерле истәлекләре тормыш иптәшенә барып тоташа. Ире сугышка киткәндә, яшь кенә Зифа берсеннән-берсе нәни дүрт бала белән калды. Нарасыйларны ятим иткән, чәчәктәй гаиләләрне сындырган, күз яшьләре түктергән сугыш халкыбызның данлы җиңүе белән тәмамланды. Үткәннәр авыр булса да, Аллага шөкер, еракта калдылар. Балалары исән-сау үсеп җиттеләр, тәрбия, белем алдылар. Хәзер зур шәһәрләрдә яшиләр. Гаиләләре белән төп йортка кайтып йөриләр, бар эшендә булышалар, кунакка дәшәләр. Йөрәк парәләре тәүфыйклы, игелекле булдылар. Ә башкача мөмкин идеме соң? Зифа әбинең күңеле гел изгелектә, эшләре гел яхшылык, теләгән теләкләре – ил-көнгә тынычлык. Бүтәнчә яшәүне тырыш авыл әбисе күз алдына да китерә алмый иде. Аллаһы Тәгаләнең барлыгына, берлегенә инанган әбинең җаны тыныч, иманы камил. Яраткан сүзләре: «Үзеңә тапшырдым, бер Ходаем». Хәзер дә яхшылыклар өмет итеп, исәнлек, сабырлык сорады.

Кара әнкә казын юксынып, утырган эскәмиясеннән кузгалды. Соңлабрак калып кайтып, сарайга кереп утырмадылар микән. Элегрәк, каз бәпкәләре үстергәндә, кичке якта кайтмый калсалар, иртәнгегә ишегалдының бер почмагында йокыларын тыныч кына дәвам итәләр иде. Каз ничә бәпкә чыгарса, шуларның барысын исән-имин үстереп әбигә тапшыра иде.

Һаман куера башлаган болытлы күкне күздән кичереп, әби өй эченә үтте.

Иртән сыер саварга чыкканда да казын күрергә өметләнеп атлады, күзенә чалынмагач, йөрәге кысылып куйды. Борчуын басарга тырышып, сыерын савып алды да, чиләген болдырга куеп, капканы ачып җибәрде. Сыерының янбашыннан чәбәкләп, көтүгә озатты. Җәйге иртә җилле-болытлы, яңгыр «менә хәзер явам» дип тора. Бәләкәй әбинең карашы капкадан ике-өч адымда утырган казга текәлеп туктап калды. «Кайттыңмы, матурым?» – дип, казга якынлашты. «Әстәгъфирулла, йа Ходаем, бу ни хәл?!» – дип иелде.

Казы, хәлсезләнеп, көчкә тынын алып утыра. Аның салынып төшкән башын канаты астына кыстырып, казның үзен култык астына алып, җитез атлап, ишегалдына керде, сарайга үтте. Бәләкәй әбинең бөтен барлыгында бер генә уй: бу ни хәл, ни булды? «И-и сабыем, хәзер, хәзер», – дия-дия оясына куйганда, кулы казның түшендәге ярага тиеп китте. Белгән догаларын укып, яра тирәсен сак кына сыйпаштырды. «Бәпкәләрең кайда соң?» – дип, салынып төшкән канатларын тигезләде, «Йә, ярар, терел генә, җайланыр», – дип, аны аркасыннан сөйде. Барысына да буйсынып битараф утырган җиреннән, кара әнкә каз Бәләкәй әбинең борчылуына нык уңайсызланды. Зифа әби, күз тирәли ялтыраган яшь бөртекләрен тыярга тырышып, иреннәрен кысып, казны оясы белән ишегалдына алып чыкты. Кинәт тоташ дивардай яңгыр коя башлады. Әби иңрәп елап җибәрде. «Кичер, Ходаем, гөнаһларым булса кичер. Илгә-көнгә тынычлык, балаларыма исәнлек-саулык, бар кешеләргә дә рәхим-шәфкать, миһербанлык бир. Йа Раббым, рәхмәтеңнән ташлама!»

Җир шарының гаҗәеп гүзәл урынында саф сулы, яшел тирәкле елга буендагы авылның гади, ак яулыклы татар әбисе яхшылык тели иде. Ул үрдәк балаларының ничек югалганын да, казның нидән авырганын да белми иде. Тормышта һәрвакыт үзенә ни кирәген, үзеннән ни кирәксенгәннәрен аңлап яшәгән Зифа әби хәзер иң яхшысы казны терелтү икәнен белә. Аны оясы белән өйгә алып керде, мич буена урнаштырды. Үзе белгәнчә шифалы үлән сулары әзерләп казына эчерде, ярасына сөртте. Шулхәтле игътибар һәм караудан әнкә казга яшәү өмете керде. Ул бертуктаусыз үрдәкләр турында уйланды. Кайда икән ул нарасыйлар, аларны кыерсытмыйлармы? Күз алдында нәни йомгаклардай үрдәкләрнең шаярышып уйнаулары, канәгатьләнеп йоклаулары торды. Колагында аларның нәфис кенә «пи-пи-пи, әни-әни» дигән тавышлары ишетелде. Ул аларны өзелеп юксынды.

...Кара казының исәнлеге өчен Зифа әбинең тырышлыгы яхшы нәтиҗәсен белдерде. Бер иртәдә ул хуҗасы белән ишегалдына чыкты. Таң беленеп килә. Таулар артыннан кызарып чыгып килгән кояшның бер чите күренде. Янәшәдәге болытлар алсу төскә манчылды. Кояш кыйпылчыгы акрынлап зурайды, ярым түгәрәк формага керде. Тау буйлап сузылган куе яшел урман, тау итәгендәге хәтфә болыннарга яктылык иңде, кояш нурлары аларның барысын да сыйпап узды, елгадагы көмеш тамчыларны барлап җемелдәде һәм ул түм-түгәрәк булып тулышты, яңа көн туды. Үрдәк бәпкәләренең югалуына эченнән хафаланса да, казын сөеп шатланды әби. Балалар, оныклар белән Коръән ашы уздырып аласы булыр дип уйлап алды.

Ул арада каз урам әйләнеп кайтты. Кайткан җиренә капка төбенә берничә җиңел машина туктаган иде. Ишегалдыннан балалар тавышы, ачык тәрәзәдән күңелле гәпләшү ишетелә.

– Әнкәй, ашны кайчан җыярбыз, токмач кисеп куйыйкмы?

– Әнкәй, мунча әзер, без печәнне алып кайтырга киттек.

– И-и балакайларым...

Кара әнкә каз «балакайлар» сүзеннән тетрәнеп китте. Балалар, сабыйлар, бәпкәләр... Үрдәкләр мине үз итте, алар өчен мин җаваплы, дип, елгага таба кузгалды. Күпердән ерак түгел елга яры сөзәк, комлы. Монда казлар, үрдәкләрнең суга кереп китү урыны, бозаулар, колыннар, атлар суга кереп басып ял итә. Кара әнкә каз да, суга үтеп, кош-кортларга карады. Сигез бәпкәле бер оя ак каз гына суда акрын тирбәлә. Кара каз агым уңаена түбәнгә юнәлде. Аска таба елганың авыл ягы яры кара балчыклы текә тау буйлап үтә, бераздан тау сөзәкләнә, тау итәгендәге чишмәләр елгага кушыла. Монда су агымы салкынча икән, аягына суык дулкын кагылды. Каз елганың уртасынарак үтте һәм агым буйлап сәяхәтен дәвам итте. Икенче як яр буйлап шомырт агачлары тезелеп киткән, баю юлына борылган кояш нурларында аларның суга тияр-тимәс ботакларындагы тәлгәшләрдә җимешләр карасу-кызгылт булып ялтырыйлар. Монда әрәмә, кычыткан, әрекмән исе килә, салмак борылыш алып, авылны елга урап үтә. Инде түбән оч йортларының бәрәңге бакчалары да күренә, алар елгага якын гына. Авылны чыктым дигәндә, ярның күпер яны башындагы кебек үйсу, комлы җире бар икән. Авылларының күркәм, мул йортлы булуына каз гаҗәпләнде. Моңсуланып, кайтыр якка борылды. Көн кичкә авышкан, эңгер-меңгер вакыт. Шунда ерактан килгән тонык кына тавышлар таныш булып ишетелде: пи-пи,бәк-бәк-бәк. Чү, аныкылар түгелме? Каз талпынып куйды. Сөзәк яр буйлап аның бәпкәләре, тыпырдап йөгереп, елгага якынлашалар иде. Артларында кулындагы нәзек чыбыкны болгап килүче юан гәүдәле ханым күренде. Шомырт агачы ышыгында булган әнкә казга алар ачык күренә. Суга җитәрәк, үрдәк бәпкәләре шым булып туктап калдылар. Алар әле елгага иялашмәгән. Бүгенге көнгә чаклы ябык урында асраганнары сизелә, шактый пычранганнар, өсләре лайлалы балчыкка буялып көрән-күк төскә кергән, хәтта борыннары таплы. Куалап килүче хатыннан куркып, алар елгага үттеләр, су өстендә тирбәлеп тынычланып калдылар. Әйе шул, суның кодрәте көчле, ул тәнгә сихәт, күңелгә дәрт өсти, чистарта, сафландыра.

→ Ахыры 10нчы биттә.

«Язлар кебек янып яшим җирдә»

Танылган әдипнең юбилее н – гомер бәйрәмен үткәрү аның үзеннән дә бигрәк укучысы өчен мөһим. Язучы туган халкына, үз укучысына никадәр якынрак булса, бәйрәм тантаналарының саны да, тәэсире дә шуның кадәр зуррак була, күрәсең.

Татарстанның халык шагыйре, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Россия Гуманитар фәннәр академиясенең шәрәфле академигы, Татарстан Дәүләт Советы депутаты Разил Вәлиевнең 70 яшьлек гомер бәйрәме дә республикабызда зур колач белән үткәрелә. Әгәр дә ул бәйрәмнәр яшьләр аудиториясендә шаулап-гөрләп уза икән, бу язучы иҗатының озын гомерле булуын һәм киләчәккә баруы турында да сөйли. Разил ага бу яктан бәхетле әдипләрнең берсе – юбилееи Казан федераль университеты үзендә зурлап үткәрде. Халык шагыйре бәйрәменә зал тутырып килгән каләмдәшләре, туганнары-дуслары, хезмәттәшләре, университет галимнәре һәм студентлар бу залда мөһим тарихи вакыйганың шаһиты булдылар. Бу көнне университет ректоры Илшат Гафуров һәм Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов үзара хезмәттәшлек килешүенә кул куйдылар. Ә бу Язучылар берлеге һәм университет телебезне саклау һәм әдәбиятыбызны үстерүдә киләчәктә дә кулга-кул тотынып эшләячәк дигән сүз.

Һәр гомер бәйрәме тантанасындагы кебек үк, монда да юбилярга ихластан әйтелгән матур теләкләр дә, истәлекле бүләкләр дә күп булды. Дустын һәм туган тел өчен көрәштәшен котларга халкыбызның тагын бер бөек шәхесе Туфан ага Миңнуллин да «килгән иде». Аның турындагы видеоязма тамашачыны үткәннәргә алып кайтып, күңелен нечкәртте. Мөхәммәт ага Мәһдиев «яшьлек җырчысы» дип атаган Разил Вәлиевне. Кичәнең «Язлар кебек янып яшим җирдә» дип аталуы да һәм аның җиребезгә язлар ишек какканда яшьлек иле булган университетта узуы да 70 яшьнең әле егет чак икәнен искәрткәндер.

Аңарчы Разил аганың юбилее Татарстан Милли музееның Флюра Дәминова җитәкләгән әдәби салонында бик җанлы узган иде. Мондый очрашуларны Флюра ханым даими үткәрә. Аларга башлыча зыялы апа-ханымнар йөри. Абзыйлар да очраштыргалый. Разил ага Вәлиев кичәсенә дә алар зал тутырып килгәннәр иде. Арада яшьләрнең, студентларның булуы да сөендерде. Ә бит мондый әдәби салоннар ике як өчен дә бик файдалы: укучы әдип белән якынрак танышып кала алса, әдип тә үз укучысының күңеленә тагын да якыная. Очрашуга килгән тамашачы Разил аганы талантлы шагыйрь, язучы итеп кенә түгел, ә тапкыр сүзле, шаян табигатьле кеше буларак та белеп китте. Разил Вәлиев тамашачыларга үзе белән булган кызыклы хәлләрне искә алып сөйләде.

– Мин бер төркем Рәсәй язучылары белән Әфганстанга бардым. Бу вакытта анда сугыш бара иде. Китәр алдыннан бик ныклап: «Сәясәткә кагылмагыз, сез язучылар гына», – дип кат-кат тукып җибәрделәр. Әфган телевидениесе Рәсәйдән килгән әдипләр белән тапшыру оештырган. Хәйләкәр журналистлар: «Дошманнарга мөнәсәбәтегез ничек?» –дип сорагач, минем башыма иң беренче «сәясәткә кагылмагыз» дигән наказ килде. Сорауны җавапсыз да калдырып булмый. «Минем монда килгәнемә әле ике генә көн, шуңа минем монда дошманнарым юк. Бөтен дошманнарым туган илдә – Казанда калды», – дип җавап бирдем, – диде.

Әдипнең шаярткнанын тамашачы аңлады, билгеле. Дошманнары булган кеше гомер бәйрәменә шуның кадәр дусларын җыя ала димени?! Хәер, әдип үзе аларның булуына рәхмәт әйтеп яши. Алар аңа яшәр өчен көч бирә икән. Көченә ышансак та, дошманнары булуына бер дә ышанасы килми күңелендә көяшлы җырлар яшәгән шагыйрьнең.

«...йә дөньяны үзгәртәм мин бүген, йә булмаса үзем үзгәрәм...» дип, беренче шигырьләрендә үк үз тавышын ишеттереп, халык мәнфәгатен кайгырткан, милли мәдәниятебез, туган телебез сагында торган. Ул бит Дәүләт Советында мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, халык язучысы юбилей мөнәсәбәтләре илә очрашулар, кичәләр уздырып, бәйрәм итеп кенә тора алмый. Ул әле күптән түгел генә ябылган, ләкин халыкныкы дигән исеме булган «Тәртип FM» радиосын яклап тыңлаучылар кул куйган ун меңләп имзаны Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка тапшырган. Хәзер бергәләп җавап көтәләр. Уңай җавап килсә, халык шагыйренең олуг гомер бәйрәменә иң зур бүләк шул булыр иде.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

Каз канаты

→ **Ахыры. Башы 9нчы биттә.**

Бәпкәләр томшыклары белән суны болгатып алдылар, як-якка чайкалып мавыгып юына башладылар. Аларның түше, нәни канатлары нәзек шома каурый белән капланса да, муен һәм койрык тирәләре мамыктан. Тиздән алар сары борынлы, ак мамыклы сөйкемле үсмер үрдәкләр кыяфәтенә кайттылар, шаярышып чумып уйный ук башладылар. Исән-саулар, дип шатланды әнкә каз, аларга карап.

Үрдәк бәпкәләрен күзәтеп торган ханым, җиргә тагарак белән җим куеп: «Үти-үти-үти», – дип чакырды. Үрдәкләр, теләр-теләмәс кенә, ярга чыктылар, савытка үрелделәр. Шул чак ханым, аларның артларына кинәт кенә үтеп: «Көш-ш!» – дип ысылдады. Үрдәк бәпкәләре сискәнеп, савытны капландырып, абынып, алга ыргылдылар. Әлеге ханым аларны бакча буендагы сукмактан сарайларына куалап алып китте. Ана каз янәдән берүзе калды. Таптым, исәннәр, дигән сөенече «Ничек Зифа әбигә белгертергә, өйгә алып кайтырга?» дигән сораулар белән алышынды. Каз елга буйлап кайтырга чыкты.

Ишегалдына кипкән печән кайтарганнар, аны әбинең уллары, кияүләре сарай түбәсенә күтәрә. Җыйнак гәүдәсенә алъяпкычын япкан әби бәхетле елмая. Каз да төшеп калган печәннәрне томшыгына элеп җыйнаштырып йөрде. Көн шулай тәмамланды. Икенче көнне таң беленү белән, елгага омтылды, кичкә чаклы авылның түбән оч буен сагалаcа да, үрдәкләрне коендырырга алып килүче булмады. Нишләсен, тагы ялгызы кайтты. Өй янында җанлану сизелә. Кояшта киптерелгән, җиллләтелгән түшәк-мендәрләрне алып керәләр, юылган челтәрләрне эләләр. Авылның мулласын, туганнарны, мөхтәрәм кешеләрне чакырып, ашка әзерләнәләр. Әби, казына карап: «Кайттыңмы, матурым?» – дип эндәште. Кара әнкә каз Бәләкәй әбинең күлмәк итәген тарткалап алды. «Сөбханалла, җыелыштык», – дип, әби капканы яба башлады. Барыбыз да түгел шул әле дигәндәй, каз елгага кире талпынды. «Йә, җайланыр, барысы да әйбәт», – дип Зифа әби, аның алдына чиста су куеп, өйгә үтте.

Каз таңны аттырды да елгага ашыкты. Су өстендә шомырт агачы ышыгында үрдәкләрне көтте. Кичке якта, ниһаять, аларның куркынып һәм ашыгып йөгерә-атлый килгән шәпкә суга кереп китүләре күренде. Озын, нәзек чыбыгын тоткан ханым яр читеннән берничә адымда. Кара әнкә каз елганың уртасынарак чыгып, үрдәк бәпкәләренә карап, тавыш бирде: «Кыйк!» Үрдәкләр аңа таба борылдылар. «Әни? Бәк-бәк, әни!» Каз өй ягына борылды. «Кыйк!» Үрдәк бәпкәләре казга иярделәр, агымга каршы йөзеп киттеләр. Яны белән торган ханым нидер сизенеп аларга борылды, «Үти-үти», – дип чакырды. Каз, аптырап калган үрдәкләргә күз ташлап: «Кыйк!» – дип дәште. Бәпкәләр җепкә таккандай, аңа ияреп, түшләрен киерә төшеп, аякларын еш-еш эшләтеп, дулкынны ярдылар. «Әй-әй! Сез кая болай?» – дип кычкыргалап, юан хатын яр кырыеннан кузгалды, елга борылышындагы калкулык өстенә үрмәләде. Исәбе – чишмәләр янында аллярына каршы төшеп, юлларын кисү. Каз һәм үрдәкләр шомланып, бар игътибарны алга таба йөзүгә юнәлттеләр, канатларын күтәрә төшеп, очарга әзерләнгәндәй тизләтеп киттеләр. Ханым да калышмады, кечкенә сулыкларга баскалап, ләмле тамчылар чәчрәтеп йөгерүен дәвам итте. Бераздан күпер яны, таныш, капкадерле өй күренде. Казның йөрәге ашкынып типте. «Ничә сукмак буйлап үтәсе?»

– Ли-ли-ли! Ли-ли... – Алсу күлмәкле Бәләкәй әби казын эзли чыккан.

– Кыйгак! Кыйк! – Кара әнкә каз канатларын җилпеп, җиргә чыгып басты.

– И-и кошкайларым, – дип, әби алар каршына якынлашты.

Кинәт чәчләре тузгыган, балчыкка буялган, ярсып сулыш алучы ханымны күреп:

– Син?.. – дип эндәште.

Аның елмаюлы йөзе бер мәл кырысланып куйды. Ханым, кулындагы чыбыгын читкә ташлап:

– Башкаларга белгертә күрмә, шайтан котыртты, – дип бурлаттай кызарып, түбән карады. Җыенаятендә тотылган авылдашына карап, Зифа әби:

– Тукта, шунда гына тор, – дип җилдәй ашыгып өйгә үтте дә, кулына төргәк тотып килеп тә чыкты.

– Мә, ал, Коръән укыткан табыннан, – дип, һаман әле карашин җирдән алмаган ханымга хуш исле икмәк сузды. – Ал, күңелеңә шикле уйлар килсә, белгән догаларыңны укы, хаталардан, рәнҗешләрдән саклан.

Хатын икмәкне күкрәгенә кысты. Башын иеп саубуллашты. Кара әнкә каз, үрдәкләр, Зифа әби аны күздән югалганчы озатып калдылар.

– Кыйгак! – Каз капка янына атлады. Анда аларны әбинең балалары, оныклары көтеп тора иде.

Тулган айлы гаҗәеп нурлы төндә, бихисап йолдызлы күк астында туган йорты ишегалдында кара әнкә каз бәпкәләре янында. Ул яхшылыкның югалмаячагына, якты эз калдырачагына ышанган иде.

Нияз Бишбалта төзеде.

Чайнворд

«Бизәнү әйберләре»

1. Каурыйсыман формадагы кыйммәтле ташлар белән бизәлгән чәч матурлау әйбере.
2. Кыйммәтле ташлардан ясалган, ирләр муенына тага торган бизәнү әйбере.
3. Кыйммәтле ташлар белән бизәлгән өч рәтле беләзек.
4. Баш түбәсен каплый торган, гадәттә сәйлән, энҗе, ука белән чигелгән түгәрәк, ирләрнең җиңел милли баш киеме.
5. Урта гасырларда ирләр өчен бармакка кия торган кашлы бизәнү әйбере.
6. Сәйлән яки энҗе белән чигелеп, бәрхеттән тегелгән, маңгай турысына киелә торган татар хатын-кызларының баш киеме.
7. Бизәкле ярымай формасындагы рус хатын-кызларының матур баш киеме.
8. Хатын-кызлар костюмы якасына беркетелә торган металлдан эшләнгән бизәнү әйбере.
9. Кашлары асылташлардан булган колак алка.
10. Урта гасырларда хатын-кызлар түшләренә кадый торган бизәнү әйбере.
11. Затлы металлдан эшләнгән кием эләктергеч (каптыргыч).
12. Элекке заманнарда русларның киемнәренә тага торган металлдан эшләнгән бөти (күз тимәстән).
13. Таштан, гәрәбәдән, пыяладан агачтан һ.б. ясалган төрле зурлыктагы төймәләрне җепкә тезеп, муенына тагу өчен ясалган бизәнү әйбере.
14. Колак йомшагына тагыла торган ясалма бизәнү әйбере.
15. Туй балдагы эшләнгән материал.

Җаваплар.
1.Эгрет **2.**Торквес **3.**Сантимент **4.**Түбәтәй **5.**Йөзек **6.**Калфак **7.**Кокошник **8.**Колье **9.**Ривьера **10.**Аграф **11.**Фибула **12.**Алам **13.**Муенса **14.**Алка **15.**Алтын.

ТӘРБИЯ

Улым, сиңа әйтәм...

Начар холыклы бер егеткә әтисе бер капчык кадак бирә һәм: «Әй улым, ачуың килеп яки кем белән булса да ачуланышканда, бакча диварына бер кадак кагып куй», – дип әйтә.

Улы беренче көнне үк 37 кадак кага, әмма көннән-көн кадакларның саны күпкә кими бара, ягъни егет әкренләп ачуын басарга өйрәнә, чөнки ул, кадаклауга караганда, ачу хисләрен тыеп калуның җиңелрәк икәнен аңлый башлый. Шулай итеп, егет ачуын тыярга өйрәнә һәм кадаклаудан бөтенләй арына. Әтисе янына барып, шушы яңалыкны хәбәр итә. Атасы аңа:

– Әй улым, хәзер инде, киресенчә, ачуың килгәндә барып, каккан кадакларыңны берәмләп кире суырып ал, – дип әйтә.

Күпмедер вакыт үткәч, әтисенә егет:

– Син кушканнарны эшләдем. Диварда бер кадак та калмады, барысын да суырып алдым, – дип әйтә.

Атасы, аны дивар янына алып барып:

– Улым, син, әлбәттә, сүземне үтәдең, ләкин диварда күпме тишек калганын күрәсеңме? Нәрсә генә эшләтсәң дә, алар баштагы халәтенә кайтмаячак инде. Әгәр син сабыр итә алмыйча берәрсе белән ачуланышып, аңа авыр сүзләр әйтсәң икән, бу гамәл аның йөрәгенә шул кадаклар кебек тәэсир итәчәк. Соңыннан күпме генә гафу үтенсәң дә (кадакларны кире суырып алган кебек), әйткән сүзләрең өчен гафу үтенсәң дә, күңелендә яралары барыбер калачак. Авыр сүз белән берәрсенең күңелен яралау кайвакыт кул белән яра ясауга караганда да катырак була. Шуңа күрә, әй улым, якыннарың, туганнарың, дусларың һәм, гомумән, кешеләр белән аралашканда, авыр сүз әйтер алдыннан бик нык уйла син. Кадак мисалын беркайчан да онытма, – дип әйтә.

Аллаһы Раббыбыз барчабызга бары тик файдалы, кирәкле сүзләр сөйләргә, ачу килгәндә ачуны йотарга һәм сабыр булырга насыйп итсә иде.

Нияз хәзрәт САБИРОВ,
«Апанай» мәчете
имам хатибы.

Бөтен кызыклы мәгълүмат
бер урында
www.shahrikazan.com

Наилә ЯХИНА

Бер ут...

Шашкан диңгез дулкыннарын талап,
ярга ташлагандай,
Ник котыра кар-бураннар авыр сулап,
Нигә болай?
Юлчы булып юлда калдым. Кыш уртасы.
Иксез-чиксез озын юллар бар үтәсе.
Сүнгән кояш, яшеренгән качып, –
Кара болыткамы?
Күзен ачмый усал күге, юл күрсәтми, –
Эз юккамы?
Авыр атлыйм. Санамыйм ла адымымны,
Чиге юктыр, буранлы юл – гүр газабы.
Күрдем кинәт, юл башында, алда,
Мине чакыргандай,
Тонык бер ут ташлый миңа ал сызыгын,
Таныгандай...
Юл башында юлымнынмы бу тәмамы?
Әллә инде ялгыз тәрәз, эше юктан,
Күзәтәме бу буранны?

ШИГЪРИ МИЗГЕЛ

Дөнья бик усал...

Дөнья бик усал. Аны мактыймммы?..
«Арбам» бик авыр, аны тартыйммы?..
Көннәрем бик тиз, йөгреп тотыйммы?..
Буйсынып җилгә, сузлып ятыйммы?..
Офыклар кызыл, хушлаша кояш,
Әвәли кичләр көнне – бик юаш...
Туачак таңны бик сак яшереп,
Ай баскан сафка, төнне тикшереп...
Син аттыр әле таңны яктырак!
Булсын бу дөнья бераз затлырак!..
Өмет тулы җан иркен төнемдә
Сиңа, Тулган ай, торам мин карап!
Син булсаң әгәр минем ягымда,
Җибәр «ярдәмче» ошбу таңымда!
Тартырбыз парлап иске арбаны
Төяп бәхетләр – әле калганын...
Дөнья бик усал... Торам мин карап...
«Арбам» ватылды...
Булдым мин «харап»!..

СОРАУ-ҖАВАП

Күп еллар инде намаз укыганым юк. Әлеге намазларны мин нинди тәртиптә каза кылырга тиеш?

– Әгәр дә кеше алтыдан артык намазын калдырмаган булса, ул аларны тәртип буенча укый. Әгәр дә аның алтыдан артык намазы укылмый калган икән, калган намазларын үзе теләгән вакытта каза кыла ала. Искәрмә булып кояш чыгу, зәвәл һәм кояш баю вакытлары тора. Әгәр кеше намазының кайчан һәм нинди көндә калдыруын белсә, ул шуларны әйтеп ният кылырга тиеш. Әгәр соңга калган намазының вакыты һәм көне билгеле булмаса, түбәндәгечә ният кылсын: «Ният кылам беренче укылмый калган (мисал өчен) иртәнге намазын укымакка» яки «Ният кылам соңгы тапкыр үтәлми калган иртәнге намазын үтәмәккә».

«Әт-Тәнвир» китабына аңлатмада «Соңга калган намазлар» бүлегендә әйтелә: «Әгәр кешенең соңга калган намазлары күп булса, ул кеше йә иң беренче, йә иң соңгы укымый калган намазына ният кылсын, мәсәлән, иртәнге намазга».

Сәхабәләрнең исемнәрен искә алган вакытта (ишеткәндә) радыяллаһу гәнһу (ягъни Аллаһы алардан разый булсын) дип әйтү мәҗбүриме?

Болай дип әйтү мәҗбүри түгел, ләкин хупланылган гамәл.

tat.islam-today.ru

КЛИНИКА ИНСАЙТ
КАЗАНЬ Н.ЧЕЛНЫ АЛЬМЕТЬЕВСК
ПЬЕТ БЛИЗКИЙ ЧЕЛОВЕК?
ПОМОЖЕМ КРУГЛОСУТОЧНО!
Вывод из запоя на дому
Вывод из запоя в стационаре
Бесплатная доставка в стационар
по Татарстану
ЛИЦЕНЗИЯ№ЛО-16-01-005820
ins-clinic.ru 8 800 505 02 74
Бесплатный звонок по России
имеются противопоказания, необходима консультация специалиста
Реклама

РЕКЛАМА
Май аенда карпатка, карника токымлы аталанган ана кортлар сатабыз
т.8-965-583-71-45 (Радик),
т.8-937-298-77-64 (Фаим)

Реклама
Требуются водители кат. C, D, E, автослесари. Вахтовый метод, зарплата сдельная.
Тел.: 8-937-581-22-01, 8-906-117-15-12 (водители), 8-917-918-10-98 (слесари), (8552) 46-67-18.

АФИША
13 - 19 МАРТ

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

14 март «Исәнме, улым!» (Б. Абдуразззоков)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 300-350 сум
15 март «Банкрот» (Г.Камал)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 200-1200 сум
16 март «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
17 март «Диләфрүз - Remake» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 19.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
18 март «Җилкәнсезләр» (К.Тинчурин)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 250-1500 сум
19 март «Агыла да болыт агыла...» (Х.Туфан, Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 300-350 сум
19 март «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 200-1200 сум

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

14 март «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 18.30
15 март «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин)
Башлана: 18.30
16 март «Алтын көз» (Ш.Фәрхетдинов, Р.Заһидуллин)
Башлана: 18.30
17 март «Назлы кияү» (К.Тинчурин)
Башлана: 18.30
18 март «Мәхәббәт баскычы» (Ш.Фәрхетдинов, Р.Заһидуллин)
Башлана: 17.00
Т.Миңнуллин исемендәге Түбән Кама татар дәүләт драма театры гастрольләре
19 март «Сысысырда ясалган...нар» (Л.Лерон)
Башлана: 12.00
19 март «Гөргери кызын бирә» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 250-600 сум

«ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

16 март «Золушка» (Ш.Перро)
Башлана: 11.00, 13.00
17 март «Щелкунчик» (Э.Т.А.Гофман)
Башлана: 11.00, 13.00
18 март «Волшебник изумрудного города» (А.Волков)
Башлана: 11.00, 13.00
19 март «Кәҗә белән Сарык» (Г.Тукай, Г.Рәхим инсц.)
Башлана: 11.00
19 март «Аленький цветочек» (С.Аксаков)
Башлана: 11.00, 13.00
Билет бәясе: 250-600 сум

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ КАЗАН ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

14 март «Әйт әле, күбәләк» (Т.Миңнуллин)
Башлана: 14.00
14 март «Артист» (Р.Зәйдулла)
Башлана: 18.30
15 март «Гашыйклар утравы» (Р.Сәгъди)
Башлана: 18.30
16 март «Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз» (И.Юзеев)
Башлана: 18.30
17 март «Убыр-шоу» (З. Хөснуллина)
Башлана: 14.00
Билет бәясе: 150-200 сум

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ
(ПАВЛЮХИН УРАМЫ, 73)

13 март Филүс Каһиров концерты. Сәхнәдә ун ел
Башлана: 18.30
Билет бәясе: 400-1200 сум
18 март «Болгар радиосы» концерты
Башлана: 18.00
Билет бәясе: 400-950 сум

УНИКС
(ПРОФЕССОР НУЖИН УРАМЫ, 2/27)

18 март «Татарча солянка»
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 650-1000 сум
19 март Ризван Хәкимов концерты
Башлана: 17.00
Билет бәясе: 500-1500 сум

«ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

«Күчеп йөрүче ХӘБӘР»ләр – Халыкара сәнгать проекты күргәзмәсе. Проект авторлары Әлфия Ильясова (Татарстан) һәм Наталья Николаева (Саха-Якутия).
Керү ирекле (эш көннәрендә).

5+

Интернет аша спортка якынаябыз

СПОРТ

sport.tatarstan.ru адресы буенча Инфо-спорт порталы эшли башлады.

– Бу порталга республикадагы 270 спорт корылмасы, 170 балалар-үсмерләр спорт мәктәбе, 40 спорт оешмасы һәм учреждениесе турында мәгълүмат тупланган. Спорт сарaeның яки корылмасының адресы, картадагы урыны, эш сәгатьләре кителә. Республиканың тренерлары исемлеге, яңалыклар һәм афишалар белән танышырга, кызыксындырган сорауларга җаваплар табарга, үзеңнең дә хәбәр-тәкъдимеңне калдырырга мөмкин, – дип хәбәр итте Хөкүмәт йортында узган брифингта республиканың яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов.

Спорт корылмаларының пенсионерларга кайсы көннәрдә бушлай хезмәт күрсәтүе турындагы белешмәләр дә куелган. Физик мөмкинлекләре чикле кешеләргә аерым игътибар бирелгән: алар биредә үзләренә кирәкле хәбәрләрне тулысынча таба ала.

– Портал республика халкы спорт, спорт секцияләре, массакүләм спорт турында белеп торсын, спортка актив кушылсын өчен оештырылды, – диде Владимир Леонов.

Республиканың элемтә һәм мәгълүматлаштыру министры Роман Шәйхетдинов әйткәнчә, Татарстанның инфо-спорт интернет порталы әле Россиядә бердәнбер.

– Портал баштагы өч айда сынау-тәҗрибә режимында эшләячәк. Киләсе елдан инфо-спорт порталының татар телендәге варианты да гамәлгә куелачак, – диде Роман Шәйхетдинов.

Татарстанда яңа «SPORTS KIDS» журналы барлыкка килде. Басманың баш редакторы Ринат Хикмәтуллин таныштырганча, әлеге журнал халыкка бушлай таратыла.

Дамир БӘДРИЕВ.

КЕРҮ ИРЕКЛЕ

10 март көнне «Рубин»ның яшьләр командасы язгы сезонда «Оренбург» белән беренче матчын уткәрә. 19нчы турның очрашуы 13.00 сәгатьтә «Рубин» стадионында башланачак. Матчка керү ирекле.

Әлегә турнир таблицасында безнекеләр җиденче урында бара. «Оренбург» исә 13нче урында.

УЕН КИЕРЕНКЕ БУЛЫРГА ОХШАГАН

Казанның «Ак Барс» командасы Континенталь хоккей лигасы көнчыгыш конференциянең ярымфиналына чыкты. Хәзер «Ак Барс» хоккейчылары Гагарин Кубогы өчен «Авангард» командасы белән көрәшәчәк.

9 март көнне «Ак Барс» плей-оффның икенче раундында Омскиның «Авангард» командасы белән очрашты. Казанлылар овертаймда 1:2 исәбе белән отты. Хәлиткеч алканы Артем Лукоянов кертте. Шулай итеп, «Ак Барс» сериядә 1:0 исәбе белән алда бара. Киләсе уен 11 мартта булачак. Казандагы матч 13, 15 мартта «Татнефть-Арена» боз сараенда узачак.

Шунысы кызык, кайчандыр «Ак Барс» өчен уйнаган Евгений Медведев бүген көндәш командасының капитаны булып тора. Бу исә уенны тагын да җанландыра. Уенга билет бәяләре дә очсызлардан түгел (600-1500 сум). Ә матч узса көндә билетлар бернича тапкыр кыйммәтрәк булачак.

КЫЗЛАР СЕРБИЯГӘ ЖЫЕНА

Казан «Динамо»сы волейболчы хатын-кызлары Европа кубогы конфедерациясе вакытында Сербиянең «Визура» командасын җиңүгә ирешә.

Соңгы турнирларга күз салсак, Сербия командасы иң көчлеләрнең берсе булып санала. Алты ел эчендә көндәш команда 15 уенда җиңү яулаган. Ләкин безнекеләр уен барышында тупны бер тапкыр да «Визура»га бирмәде. Нәтиҗәдә 3:0 белән «Динамо» җиңүгә ирешә. Хәзер Казан спортчылары Сербиягә җыена.

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843). 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1668. Гомуми тираж – 6338.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 686. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843). 562-50-12,
факс: (843). 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы